ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# ТҮЛӘК КИТАБЫ

## ДАСТАН

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# ТҮЛӘК КИТАБЫ

дастан

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2008

УДК 821.512.145 + 902/904
ББК 84 (2Рос=Тат) + 63.2
Т11

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм махсус мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

**Түләк китабы:** дастан / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли
Т11 китап» нәшрияты, 2008. – 76 б. – («Татар археографиясе» сериясе;
2 нче китап).
ISBN 978-5-88473-047-2

Бу китапта тирән мәгънәле һәм мавыктыргыч сюжетлы борынгы татар дастанының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган, XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән кульязма тексты һәм аның турындагы мәкаләләр тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145 + 902/904
ББК 84 (2Рос=Тат) + 63.2

ISBN 978-5-88473-047-2

© Мәрданов Р.Ф., 2008
© «Милли китап» нәшрияты, 2008

# «ТҮЛӘК» ДАСТАНЫНЫҢ ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘГЕ КУЛЪЯЗМА НӨСХӘСЕ

«Түләк китабы» (Түләк белән Сусылу) – татар халкының гасырлар аша хәзергәчә килеп ирешкән борынгы дастаны. Төрки-татарлар элек-электән аны укып мәгънә һәм фикер, юаныч һәм ләззәт алып килгәннәр. Татар-башкортлар яшәгән төбәкләрдә дастанның язма текстлары да кулланылган һәм халык иҗатында телдән-телгә сөйләнгән вариантлары да сакланган.

Мавыктыргыч бу әсәр башка халык вәкилләренең, шул исәптән рус галимнәренең дә, игътибарын җәлеп иткән. XIX гасыр тел галиме В.И.Даль Дим буе башкортларыннан язып алган вариантын рус телендә 1843 елда «Москвитянин» журналында бастыра[1]. (Әсәрнең бу версиясе 1959 елда башкортчага тәрҗемәдә дөнья күрә). Аннан соң әлеге дастанга Лев Суходольский игътибар итә. Ул Уфа татарларыннан дастанның эчтәлеген язып ала һәм 1858 елда бастырып чыгара[2]. Р.Г.Игнатьев Оренбург губернасы типтәрләреннән әсәрнең икенче бер вариантын язып алып, «Сказка о Сари-Сагибе, сыне Абдрахманова» исеме белән 1875 елда нәшер итә[3]. Ул Уфа башкортлары арасында нәкъ шуңа охшаш әкиятнең сөйләнүен, аның төп герое Түләк, аның әтисе Сары-Маркас булуын искәрткән[4]. Рус галиме Г.И.Потанин 1892 елда дастанның бүтән халыклар авыз иҗаты белән аваздашлыгын өйрәнеп махсус мәкалә

[1] Даль В. Башкирская русалка // Москвитянин. – 1843. – № 1. – С. 97–119.

[2] Суходольский Л. Легенда о Туляке // Вестник императорского Русского географического общества. Ч. 24. – СПб, 1858. – С. 65–72.

[3] Игнатьев Р. Сказания, сказки и песни, сохранившиеся в рукописях татарской письменности и в устных пересказах у инородцев-магометан Оренбургского края // Записки Оренбургского отдела императорского Русского географического общества. Вып. 3. – Оренбург, 1875. – С. 207–211.

[4] Шунда ук. – Б. 211.

бастырган[5]. Солтангәрәй Солтанов XX гасыр башында дастанның рус телендә янә бер вариантын рус матбугатында чыгарган[6].

Мәшһүр шагыйрь Мәҗит Гафури 1910 елда әсәрне татар телендә аерым китапчык итеп бастырган[7]. Автор 1910 елның 15 февралендә бу китабына язган «Сүз башы»нда үзенең бер ел элек Бәләбәй өязенә баруын, анда «Заятүләк»нең көен җырлап уйнауларын, «Заятүләк» дигән китап та бар дип хәбәр итүләрен тасвирлый[8]. Аннан соң ул сүзен болай дәвам итә: «Мин элек бу китапның Уфада мәшһүр бер зат тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, үзе вафат улуы сәбәпле бастырылмый калганын ишеткән идем. Монда да бунын барлыгын ишеткәч, аны шундук эзләп таптым. Кулыма төшкән мөтәгаддид (*берничә – Р.М.*) нөсхәләрне бергә китереп караганда, китапның әһәмияте мин уйлаганча булмаса да, түбәндәге сәбәпләр өчен язып алып, тугры килсә табыг (*нәшер – Р.М.*) кылдырырмын дип уйладым[9]». Димәк, М.Гафури дастанның «мөтәгаддид» (берничә) кулъязма нөсхәләрен чагыштырып, әсәрне үз хикәяләвендә язган. Аның вариантында әсәрнең чәчмә өлешләре шактый гади тел белән язылган булса, Түләк һәм Сусылу үзара әйтешкән җырлар белән такмакларның, киресенчә, архаиклыгы күренеп тора. Ягъни, М.Гафуриның дастандагы тезмә өлешләрне турыдан-туры кулъязма чыганаклардан алганлыгы аңлашыла. «Түләк китабы»ның соңгы чорда Казан галимнәре тарафыннан табылган кулъязма нөсхәләрендәге текстлар белән чагыштырып караганда, бу мәсьәлә тагын да яхшырак күзаллана. Дастанның М.Гафури версиясе әдип әсәрләренең соңгырак чыккан басмаларында яңадан дөнья күргән, башкорт халык иҗатына багышланган җыентыкларга да кертелгән.

---

[5] Потанин Г.И. Дочь моря в степном эпосе // Этнографическое обозрение. Кн. XII. – 1892. – № 1. – С. 38–69.

[6] Султанов С. Зоя-Тюляк и Су-сулу: башкирское предание // Самарская газета. – 1902. – № 83.

[7] Гафури М. Заятүләк берлә Сусылу: башкорт хикәясеннән. – Уфа: «Кәримев, Хөсәенев вә шөрәкясе», 1910. – 24 б.

[8] Шунда ук. – Б. 2-3.

[9] Шунда ук. – Б. 3.

Күренекле әдип һәм галим Нәкый Исәнбәт, «Түләк» дастаның кулъязмаларына нигезләнеп, 1929 елда пьеса иҗат итә башлаган. Аннары шагыйрь Муса Җәлил тәкъдиме белән опера өчен либретто язган. Татар дәүләт опера театрының ул вакыттагы әдәби бүлеге мөдире, шагыйрь М.Җәлил шушы либретто планына язган рецензиясендә әсәрнең төп мәгънәсен «...туган илгә чиксез мәхәббәт, туган илне коткару өчен һәртөрле шәхси бәхеттән баш тарту» дип билгеләгән[10]. Н.Исәнбәт сайланма әсәрләре җыентыгында «Түләк» драматик поэмасы 1942 елда язылды дип күрсәтелгән[11]. Әсәрнең тексты 1944 елда «Совет әдәбияты» журналында басылып чыккан[12] һәм соңрак әдипнең өч томлы әсәрләр җыентыгында да дөнья күргән[13]. Г.Шамуков әлеге әсәрне бәяләп болай язган: «Нәкый Исәнбәт Бөек Ватан сугышы елларында «Түләк батыр» исемле драматик поэмасын тудырды. Әсәрнең төп идеясе: кеше үз иленнән, үз халкыннан читтә яки хыяллар дөньясында гына бәхетле яши алмый. Совет Ватаны өчен каты көрәш барган чорда барлыкка килгән бу әсәр кешеләрне патриотлык рухында тәрбияләү хезмәтен үтәде һәм үти. Композитор Нәҗип Җиһанов поэмага нигезләп «Түләк» операсын иҗат итте[14]». Опера Бөек Ватан сугышы елларында һәм 1970 нче елларда сәхнәдә уйналган[15]. Н.Исәнбәт бу әсәрен иҗат итеп борынгы халык дастанына яңача яшәеш биргән.

Совет чорында Башкортстан галимнәре тарафыннан дастанның телдән сөйләнгән ике дистәгә якын варианты язып алынган һәм аларны өйрәнүгә күп тырышлык куелган[16].

---

[10] Җәлил М. Әсәрләр: дүрт томда. Т.4. – Казан: Татар. китап нәшр., 1976. – Б. 465. Рецензиянең язылган елы төгәл билгеле түгел, шулай да автор кулъязмасында 1940 елга караган өстәмә язу бар.
[11] Исәнбәт Н. Сайланма әсәрләр: өч томда. Т. 1. – Казан: Татар. китап нәшр., 1960. – Б. 452.
[12] Исәнбәт Н. Түләк батыр: опера өчен либретто // Совет әдәбияты. – 1944. – № 4. – Б. 27–36; № 5. – Б. 25–33.
[13] Исәнбәт Н. Сайланма әсәрләр: өч томда. Т. 1. – Казан: Татар. китап нәшр., 1960. – Б. 311–367.
[14] Шунда ук. – Б. 14.
[15] Татар халык иҗаты: дастаннар / төз., кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.Әхмәтова. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 350.
[16] Башкорт халык ижады: эпос. Беренсе китап. – Өфе, 1972. – Б. 7–29, 187–222, 305–316; Башкирский народный эпос. – М., 1977. – С. 8–51, 206–215, 418–427.

Дастанның татар җирлегендә табылган кульязмалары матбугатта нәшер ителгәнче, авыз иҗатының бу ядкәре турында Фатыйх Урманчеевның әтрафлы мәкаләләре чыккан иде[17]. Галим дастан эчтәлегендә чагылыш тапкан төрле дәвер мотивларын ачып, аны башка халыкларның авыз иҗаты ядкәрләре белән чагыштырып өйрәнде.

Үзенең иҗат ителү вакыты белән XIII–XV йөзләргә нисбәт ителгән «Түләк» дастанының моңарчы фәндә берничә кульязмасы мәгълүм иде. Ягъни,

1) Нәкый Исәнбәт архивындагы дефектлы нөсхә, күчерелү вакыты билгесез;

2) Казан дәүләт университетының Миркасыйм Госманов җитәкчелегендәге археографик экспедициясе вакытында 1969 елда Кама Тамагы районының Олы Кариле авылында табылган, XIX йөзнең икенче яртысында күчерелгән нөсхә;

3) 1985 елда Казанда Марсель Әхмәтҗанов тапкан, 1877 елда күчерелгән һәм тексты тулы хәлендә сакланган нөсхә;

4) 1994 елда Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында шулай ук М.Әхмәтҗанов тапкан, XVIII йөзнең икенче яртысына караган нөсхә.

Болардан икесенең (2 һәм 3 саннары белән күрсәтелгәннәренең) текстлары берничә мәртәбә басылды[18]. М.Госманов дастанның

---

[17] Урманчеев Ф. Татарско-башкирское сказание о Туляке // Советская тюркология. – 1979. – № 6. – С. 14–22; Урманчеев Ф. Героический эпос татарского народа. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 72–89.

[18] М.Госманов табып өйрәнгән текст басылды: Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 180–198; Татар халык иҗаты: дастаннар / төз., кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.Әхмәтова. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 123–135; Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыландырылган икенче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – Б.237–254; Башкорт халык ижады: өсөнсө том. Эпос. – Өфө: Башкортостан «Китап» нәшр., 1998. – Б. 368–384, 388–393; Заятүләк менән Һыуһылыу // Ватандаш. – 1998. – № 2. – Б. 67-74 (хәзерге башкорт әдәби теленә тәрҗемәдә); Татар эпосы. Дастаннар / төз., кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.Әхмәтова-Урманче. – Казан: «Раннур» нәшр., 2004. – Б. 227–241. – Шул ук кульязманың бер битенең фотокүчермәсе Мәскәүдә нәшер ителгән «Памятники Отечества: Альманах Всероссийского общества охраны памятников истории и культуры» җыентыгының 1989 елгы 1 нче чыгарылышында (118 биттә) басылып чыкты. Тик аның аңлатма язуы «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (Листы списка поэмы «Кысса-и Йусуф» поэта XIII века Кау Гали) дип ялгыш һәм хәреф хаталары белән бирелгән.

текстын тәфсилләп өйрәнеп, аның иҗат ителгән чорын һәм җирлеген, таралыш даирәсен һәм телен фәнни яктан анализлап, әтрафлы мәкалә белән бергә бастырып чыгарды[19]. М.Әхмәтҗанов 1985 елда Казанда табылган тулы нөсхә турында мәгълүмат бирде һәм дастан текстының телен өйрәнеп, махсус мәкалә язды[20]. И.Закирова дастанның кулъязма текстларын һәм телдән сөйләнгән вариантларын башка халыклар мифологиясе һәм фольклоры белән чагыштырып тикшерде[21]. Әлеге кызыклы әсәргә Төркиядәге милләттәшләребез дә әһәмият бирде. Сафия Имре, дастан турында кыскача мәгълүмат биреп, М.Госманов китабы нигезендә текстның кыскартылган вариантын төрек теленә тәрҗемәдә бастырып чыгарды[22].

Казан галимнәре дастанның кулъязма текстларын табып һәм бастырып чыгаргач, Уфадагы кайберәүләр әлеге фактны өнәп бетермәделәр. Дастанның башкорт халкының гына мирасы булмау мәсьәләсе М.Госмановның «Каурый каләм эзеннән» китабында тәфсилләп һәм ачык итеп аңлатылган. Шунлыктан, без бу хакыйкатьне кабатлап торуны кирәк тапмыйбыз. Бары тик бер мисалны китерү белән чикләнәбез. Дастанның М.Госманов нәшер иткән тексты хәзерге башкорт әдәби теленә тәрҗемәдә бирелгән вариантның кереш сүзендә мондый юллар бар: «Татар галимдары 60-сы йылдарза хәзерге Татарстан Республикаһының Кама тамагы районында (элекке Өфө губернаһының Миңзәлә өйәзе территория-

---

М.Әхмәтҗанов табып өйрәнгән текст басылды: Әхмәтҗанов М. Түләк белән Сусылу // Әдәби мирас (Дүртенче китап). – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – Б.14-33; Түләк китабы (дастан) / журналга М.Әхмәтҗанов әзерләде // Мирас. – 2002. – № 2. – Б. 19–30; XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия / төз., искәрмәләрне һәм аңлатмаларны әзерләүче М.Әхмәтҗанов. – Казан: «Дом печати» нәшр., 2006. – Б. 284–305. – М.Әхмәтҗанов тарафыннан Олы Мәңгәр авылында табылган кулъязманың ике битенең фотокүчермәсе галимнең «Олы Мәңгәр авылы тарихы» (Казан, 2000) китабындагы фоторәсемнәр тупламында басылды.

[19] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б.170–238.

[20] Ахметзянов М. Казанский список дастана «Туляк и Суслу» // Старотатарский литературный язык: исследования и тексты. – Казань: АН СССР, Ин-т языка, литературы и истории им. Г.Ибрагимова, 1991. – С. 89–97.

[21] Закирова И. Су кызы эзеннән... // Гыйльми язмалар=Ученые записки. 7 чыг. – Казан: Татар дәүләт гуманитар ин-ты, 1999. – Б. 69–77.

[22] İmre Safiye. «Tülek ile Susılu» veya «Ayaz Tülek». Bir başkurt-tatar hikayesi // KIRIM. – 1998. – Yıl: 6. Sayı: 24. Temmuz-Agustos-Eylul.

һында) «Заятүләк менән Һыуһылу» эпосының бер кулъязмасын табып алалар һәм уны татар халык эпосы тип бастырып сыгаралар. Тимәк, был эпос кулъязма хәлендә Миңзәлә башкорттары араһында ла таралган булган. Уны язма төрки телендә язылыуына карап кына башкорт милли кобайырын татар дастаны тип һанарга милли ерлеге лә, үз эпик традицияһы ла юк[23]». Бу юлларны язган автор үзенчә куана, эченнән каһкаһәләп көлә, имеш, Кама Тамагы районында табылса да, ул барыбер башкортныкы булып чыга бит дип сөенә. Чөнки ул төбәк элек Уфа губернасының Минзәлә өязенә кергән, янәсе. Вәләкин, чынбарлыкта, әлеге губерна һәм өяздән шактый ерактагы, Идел елгасының аргы ягында урнашкан Кама Тамагы төбәге һичкайчан Уфа губернасына кермәгән. «Бөек тарихчы-географ» Кама Тамагын әлеге язмасында Түбән Кама белән буталган. Без фәкыйрегез заманыбызның мондый «птолемей»ларына Каманың ниндидер күл генә түгеллеген, бик озын, мул сулы һәм тирән бер елга булуын, шулай ук аның буенда кала-салалар әллә ничаклы икәнен, тик берсе генә Кама Тамагы исемен йөрткәнлеген искәртергә мәҗбүрбез. «Бөек гыйльми ачышлар»дан башлары әйләнгән, фән тирәсендә базар ясап йөргән шундый сукбайларның гаять киң мәдәни һәм рухи мирас дәрьябызны бер кисмәккә сыйдырмакчы булып җәфаланулары ничек беркатлы хыялыйлык булса, алар белән мәгънәсез бәхәс куертып яткан сурәттә, без дә шундый ук тинтәк кыяфәттә калыр идек.

* * *

Дастанның алда әйтеп үтелгән кулъязмаларына соңгырак заманда «Түләк китабы»ның тагын бер (бишенче) күчермәсе өстәлде. 1996 елның апрель аенда Самара өлкәсенең Камышлы һәм Оренбург өлкәсенең Северный районнарындагы татар авылларына махсус археографик сәфәр оештырган идек. Берничә көн эчендә табылган 160 берәмлек кызыклы кулъязма истәлекләр арасында аеруча әһәмиятле хәзинә – «Түләк» дастанының Камышлы авылы мәчетеннән 11 апрельдә алынган яңа күчермәсе булды. Бу хакта иң әүвәл Самара өлкәсендә нәшер ителә торган «Бердәмлек» газетасын-

[23] Заятүләк менән Һыуһылыу // Ватандаш. – 1998. – № 2. – Б. 66-67.

да хәбәр иттек[24]. Аннан соң кызыклы табышыбыз турында «Китапханә хәбәрләре» һәм «Казан утлары» журналларында 2002 елда кыскача язып үттек[25]. «Түләк-Сусылу» дастанының яңа табылган Камышлы нөсхәсен текстологик тикшереп, тирәнтен өйрәнүне киләчәктәге бурычларыбызның берсе дип, үзебезгә йөкләп куйган идек[26]. Менә, ниһаять, аның нәүбәте җитте.

Дастанның эчтәлеге һәм төп идеясе белгечләр тарафыннан моңарчы тәфсилләп һәм әтрафлы яктыртылды. Кыска гына итеп әйтергә теләсәк, дастанның мәгънәсен үзендә язылган «Ир – туган җирендә, эт – туйган җирендә газиз» дигән канатлы гыйбарәдән дә төгәлрәк аңлатып булмас кебек. Без әсәрнең эчтәлек-сюжет корылышына тукталып тормыйча, яңа табылган текстны тәкъдим итү һәм аның үзенчәлекләрен күрсәтү белән чикләнәбез.

Дастан XIX йөзнең беренче яртысында күчерелгән җыентыкның 4–14 нче кәгазьләренә теркәлгән. Җыентыкта «Түләк» дастаныннан тыш төрки телдәге шигъри бер әсәрнең ахыргы өлеше, Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәре, дини эчтәлекле язмалар урын алган. Кульязманың кайбер битләре дефектлы. Җыентыкның 36б кәгазендә «ошпу[27] төбне йазгучы мулла Сибгатулла бине мулла Фәхретдин мөдәррис, мөхтәсиб Багданов» дигән юллар бар. Дастан тексты да шул ук кеше кулы белән күчерелгән. Димәк, монысын, билгеле булган кульязмаларындагы кебек, «белеме утырып җитмәгән яшь шәкерт» кенә түгел, ә мулла кеше күчергән булып чыга. Тик аның да хаталары, кимчелекләре бар һәм бу табигый. Ул кешенең тормыш-көнкүреш шартларын һәм мөмкинлекләрен бөтенләй белмәгән хәлдә, язуына карап кына, бүгенге көн югарылыгыннан торып, аны наданлыкта гаепләү һәм яманлау һич килешмәс иде. Үз нәүбәтебездә, XIX гасыр мулласыннан хәзерге заман академик белемен таләп итеп дәгъва белдерергә әхлакый хакыбыз юклыгын да онытмыйк. Борынгы кыйммәтле әдәби ядкәрне

[24] Мәрдан Р. Якутлар табыладыр вакыт белән... // Бердәмлек. – 1996. – 2–8 июль.
[25] Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре=Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15; Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 127–128.
[26] Казан утлары. – 2002. – № 3.– Б. 128.
[27] Кульязмада «ошбу» сүзендәге «б» урынына нәкъ шулай – «п» хәрефе язылган.

кәгазьгә теркәп калдырганы өчен Сибгатулла хәзрәткә чиксез рәхмәтле булып, шөкер кылу хәерлерәк.

Бу җыентыкны күчереп язган Сибгатулла Фәхретдин улы Багдановның кем булганлыгын архивларда эзләнү нәтиҗәсендә ачыклауга ирештек. Аның ата-бабаларының төп чыгышы Казан губернасының Чистай өязендәге (хәзер районында) Мөслим авылыннан булып, алар Олы Тигәнәле авылында (хәзерге Әлки районында) яшәп, муллалык иткәннәр. Әтисе Фәхретдин Вәлишаһ улы XIX гасыр башында шул авылда имам, мөдәррис, мөхтәсиб булып торган, бабасы да – Вәлишаһ бине Мансур бине Галикәй бине Багдан мулла булган. Сибгатулла Багданов (1820–1875) олыгайган әтисен алмаштырып 1845 елдан имамлык иткән, 1857 елдан Спас өязенең ахуны вазыйфасын үтәгән, Уфадагы Диния нәзарәте идарәсенә сайланып, андагы казыйлык хезмәтендә тырышлыгы белән танылган. Сибгатулла хәзрәт вафатына кадәр Олы Тигәнәледә имам булып, аны улы Мөхәммәтвагыйз (1850 елда туган) алыштырган. Гомумән, Багдановлар нәселе вәкилләре ул авылда 1920 нче елларга кадәр муллалык иткәннәр.

«Түләк» дастаны теркәлгән җыентыкның кәгазендә су билгесе белән 1832 һәм 1834 еллар белдерелгән. Шулай итеп, дастанның язма тексты моңарчы матбугатта басылган вариантлардан әүвәлгерәк. Аны якынча 1834–1850 еллар арасында, ягъни XIX гасырның икенче чирегендә язылган дип билгеләргә мөмкин. Кулъязманы күчергән С.Багдановның XIX гасыр урталарына караган Нәзарәт документларында теркәлгән язуларының рәвеше «Түләк» дастаны текстын язганнан соң күпкә шомарган булуы да моны раслый.

Бу кулъязма җыентык хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1761 т» шифры белән саклана.

Әсәр текстының күләме тулы диярлек. Башындагы бер бит чамасы өлеше кулъязма җыентыкта сакланмаган. Ике-өч биттән соңгы тагын бер кәгазе төшеп югалган. Кулъязма ахырындарак 5-6 җөмлә күчерелмичә, буш урын калдырылган. Әсәрнең ахыры бар, әмма ул кыскартылган, гадиләштерелгән вариантта. Дастанның исеме бу кулъязмада ничек бирелгән булгандыр, кулъязманың башлангыч өлеше сакланмау сәбәпле, ул билгесез. Без аны, әсәрнең

моңарчы мәгълүм язма текстларыннан М.Әхмәтҗанов тапкан вариантында бирелгәнчә, шартлы рәвештә «Түләк китабы» дип атауны мәгъкуль күрдек һәм бу җыентыкка дастанның исемен шулай дип куйдык та.

Яңа табылган дастан тексты, моңарчы билгеле кулъязма вариантлар белән нигездә тәңгәл килә, зур аермалары юк. Әмма һәр археографик табыш үзенчәлекле була. Чагыштырып тикшерү нәтиҗәсендә Татарстан Милли китапханәсендәге текстның аерым очракларда М.Әхмәтҗанов бастырганына охшаш, ә урыны-урыны белән М.Госманов чыгарган текстка якынрак, кайбер сүзләрнең һәм җыр юлларының исә бары тик М.Гафури варианты белән генә аваздаш булуы күренә. Шулай ук дүрт вариантта дүрт төрле язылган сүзләр, сүзтезмәләр һәм аерым җөмләләр дә бар.

Билгеле булган татарча язма текстларның һәммәсендә дә дастан героеның исеме Түләк дип бирелә. Ә М.Гафури китабында ул Заятүләк диелгән. Дастанның телдән сөйләнгән вариантларында да ул, нигездә, Заятүләк дип әйтелә. Без басмага тәкъдим итә торган кулъязмада кыз тарафыннан әйтелгән:

«Сары Мыркас угълы сән,
Гайан Түләк атлигь сән» *(5а кәгазь)*

– юлларындагы «гайан» сүзе игътибарны җәлеп итә. Бу юллар М.Әхмәтҗанов бастырган текстта «Хәйба Түләк угълысын» рәвешендә басылган. Безнең очрактагы «гайан» сүзе Түләк исеменең кушма бер өлеше булып, егетнең тулы исеме Гаянтүләк булганлыкны белдерүе дә мөмкин. Шулай ук, гарәп телендәге «гайан» сүзенең «билгеле, ап-ачык, күзгә күренеп торган» дигән мәгънәләрне аңлатуын исәпкә алганда, аерым бер сыйфатлама рәвешендә кулланылган булуы да ихтимал. Ягъни, кыз өчен аның Түләк булуы бер дә сер түгел, аермачык билгеле дип аңларга була. Ә бәлки, «гайан» сүзе «зая»ны бозып язудан киткәндер? Моның хикмәте, ихтимал, киләчәктәге табышлар һәм тикшеренүләр нәтиҗәсендә ачыкланыр. Кулъязмаларда шулай ук «зифа (зиба) Түләк» буларак язылыштагы «зифа» (زيفا), «зиба» (زيبا), М.Гафури вариантындагыча «Заятүләк» язылышындагы «зая» (زايا) һәм бу кулъязмадагы «гайан» (عيان) сүзләренең гарәпчә язылышта бер-беренә охшашлыгын игътибарга ал-

ганда, боларны электәге бер үк сүзнең язылышыннан хасил булган вариацияләр дип фаразларга мөмкин. М.Әхмәтҗанов текстындагы «хәйба» сүзе дә, ихтимал, элеккегерәк берәр кульязмадагы «зиба» (ضيبا) сүзеннән бозылгандыр.

Бу кульязмада су патшасының (ханының) исеме Чачлар рәвешендә язылган. Дастанның билгеле булган башка текстларында ул Чачдар һәм Җаждар буларак язылган. Җаждар дигәненең хикмәте – «ч» хәрефе урынына «җ» язудан килеп чыкканлыгы аңлашыла. Ә Чачлар дигән язылыш, протографтан күчерүче (бәлки протографны күчергән әүвәлгерәк) кешенең «чач» дигәннән соң килә торган «د» (дәл) хәрефен бераз биегрәк итеп язып, «ا» (ләм) хәрефенә охшатып җибәрүеннән чыккан дип саныйбыз. М.Гафури текстында бу исем Чачуар дип язылган һәм әдип аны «Саче вар» (ягъни, чәче бар) сүзеннән чыккан дип фаразлаган[28]. Бу очракта исә Чачдар исемендәге «د» (дәл) хәрефенең М.Гафури үзе кулланган кульязма текстта «و» (уау) хәрефе белән язылган булуыннан, яки шагыйрьнең «дәл»не «уау» дип кабул иткәнлегеннән килә.

Егет белән кыз бер-берсенә әйтешкән җыр һәм кушагълар кульязманың текстында хәзерге шигъри юллар кебек тезмә рәвештә бирелмәгәннәр. Алар чәчмә әсәрдәге тоташ текст шикелле язылып, шигъри юллар арасында икешәр, өчәр, дүртәр һәм бишәр түгәрәкле чәчәксыман бизәкләр белән аерып билгеләнгән. Бу кульязмадагы җырлар дастанның башка мәгълүм текстлары белән, нигездә, тәңгәл килә. Әмма, сирәк булса да, үзгәлекләр күренә. Әлеге кульязмада төшеп калган строфалар булган кебек, бүтән текстларда булмаган яңалары да бар.

Милли китапханәдәге кульязмада кушагъларның ахыргы строфалары икешәр мәртәбә кабатлана. Мәсәлән, шуларның кайберләре:

«...Сүзең әйтче, Сусылу,
Сүзең әйтче, Сусылу!» *(4б кәгазь)*

---

[28] Гафури М. Күрсәтелгән әсәр. – Б. 11.

«...Зифа Түләк, йәш угыл,
Зифа Түләк, йәш угыл!» *(5а кәгазь)*

«...Кайтуб киткел, Түләгем,
Кайтуб киткел, Түләгем!» *(5а кәгазь)*

«...Сәнең берлән булайын,
Сәнең берлән булайын!» *(5б кәгазь)*

«...Балкан тагъга охшатуб,
Балкан тагъга охшатуб.» *(10б кәгазь)*

Икешәр юлдан торган мондый кабатлаулар булган кебек, дүрт юллысы да бар. Мәсәлән, кульъязманың 7б кәгазендә:

«...Теләгеңне Хак бирүр,
Давыкмачы, бай угълы!
Теләгеңне Хак бирүр,
Давыкмачы, бай угълы!»

Җыр-кушагъларның ахыргы юлларын болай кабатлаулар, һичшиксез, әсәрнең поэтик аһәңен көчәйтә һәм бизи. Мондый үзенчәлек башка кульъязма текстларда юк, ул бары тик М.Гафури бастырган текстта гына күзәтелә[29]. Боларга охшаш кабатлаулар (шул ук шигъри үлчәмдә) Нәкый Исәнбәт либреттосының текстында:

«Алман тавым бу түгел,
Алман тавым бу түгел»

рәвешендә урын тапкан[30].

Татарстан Милли китапханәсендәге кульъязмада бүтән кульъязмаларда булмаган җыр һәм кушагъ юллары яки аларның аерым өлешләре бар. Мәсәлән, Түләк кызга әйткәндәге

«...Бога кылы кув алган.
Кош очкыры чүрәкәй,
Канат какмай шуны алган» *(5а кәгазь)*

– юлларының беренче юлы бер текстта да юк, ә икенче һәм өченче юллары М.Гафури текстында бар[31].

[29] Гафури М. Күрсәтелгән әсәр. – Б. 12–16, 22-23.
[30] Исәнбәт Н. Күрсәтелгән китап. – Б. 347.
[31] Гафури М. Күрсәтелгән әсәр. – Б. 13.

Милли китапханәдәге кулъязманың 5б кәгазендә «Билне салуб суна алган» дигән юлның мәгънәсенә дә тукталып китик. М.Әхмәтҗанов текстында ул «Били салып суна алган» дип һәм «суна» сүзенә «киек» мәгънәсендәге аңлатма бирелгән[32]. М.Госманов бастырган текстта «Билән сайын сан алган» сыйфатында тәкъдим ителгән, шунда ук «билән»нең – калкулык яки кечерәк тау булуы, «сан»ның – дәрәҗә дигәнне белдерүе искәртелгән[33]. М.Гафурида бу юл «Муйны сунык суна алган» дип басылган[34]. Анда «Заятүләкнең кошы «сигез суна» дигән кошны куып тотты...» дип, «суна» сүзе кош мәгънәсендә аңлатылган[35]. Н.Исәнбәт әсәрендә дә «суна» сүзе кош мәгънәсен белдерә һәм «Хан кызына сый булырлык суна», «Бәхетебездән суна очса» дип югары бәяләнә. «Суна» – кыр үрдәгенең асыл бер төре дип, автор тарафыннан искәрмә бирелә[36]. Чынлыкта да, төрки телләрдә «суна» сүзе элек ата үрдәк мәгънәсен белдергән[37]. Димәк, «суна алу» дигәндә ау вакытында суна кошын тоту турында сүз барганлыгы аңлашыла. Бездәге кулъязмада «билне» дип ялгыш язылган сүзне «билән» рәвешендә дөресләп укыганда (М.Госманов текстында ул шулай язылган да) контекстта «билән»нең «сал» мәгънәсендә кулланылганлыгы ачыклана[38]. Шулай итеп, дастандагы «Билән салып суна алган» дигән сүзләр суга (күлгә) сал төшереп үрдәк аулауны белдерә.

---

[32] Мирас. – 2002. – № 2. – Б. 20.
[33] Госманов М. Каурый каләм..., 1994. – Б. 241.
[34] Гафури М. Күрсәтелгән әсәр. – Б. 13.
[35] Шунда ук. – Б. 8.
[36] Исәнбәт Н. Күрсәтелгән китап.– Б. 313.
[37] Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык / сост. Будагов Л. Т. I. – СПб.: тип. Имп. АН, 1869. – С. 649.
[38] «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (1 том, 1977. – Б. 165) «агач төяп агыза торган баржа» мәгънәсен белдергән «билән» сүзе бар.
Бу сүз (бәйлән вариантында) шулай ук «Болгар иленең кызлары» исемле борынгы татар җырындагы

«Иш суыннан бәйлән ага
Сары Чингә, Итилгә...»

– дигән юлларда да сал мәгънәсен белдерә.

М.Әхмәтҗанов бастырган тексттагы:

«Караңгига утырткан,
Алтын киезгә ултырткан...[39]»

– дип Түләк әйткән сүзләрнең беренче юлы М.Госманов текстында бөтенләй юк. Ә икенче юлы

«Алтын тезегә ултырган...»

– рәвешендә басылган һәм «тезегә» сүзенең «тәхеткә» булуы да ихтимал диелгән[40].

Менә бу юллар безнең кулъязмада:

«Кара кешкә ураткан,
Алтун тезгә ултурткан...» *(5б кәгазь)*

– дип теркәлгәннәр. Боларның беренче юлы кара кеш (җәнлек) тиресенә чорнау-төрү, киендерү мәгънәсен белдерә. Икенче юлындагы «тез» сүзе борынгы төрки телдә «ияр», «өзәңге» мәгънәләрендә йөргән. Ягъни, «Алтун тезгә ултурткан» дигәндә алтын ияргә утырту турында сүз барганлыгы аңлашыла. Тез (тәз) сүзе, гомумән, атның түсенә яки атка бәйле җиһазларга, атны бизәү яки җигү әсбапларына бәйле мәгънәдән чыккан. Хәзерге татар телендәге «тезген» сүзе дә шул тамырдан. «Тәз» сүзе – элек алмачуар ат дигәнне белдергән. Татар теленең кайбер сөйләшләрендә атны кыңгыраулар тагып бизәү хәзер дә «тезү» дип атала.

Соңгы табылган кулъязма белән бүтәннәрен чагыштыру нигезендә дастан текстындагы серлерәк бүтән мәгънәләр дә чишелә. Без аларның һәммәсенә дә тукталмыйбыз, чөнки ул китап ахырында бирелгән чагыштырма таблицадан яхшы шәйләнә.

Яңа кулъязма дастанның текстына «табышмаклар» да өсти. Мәсәлән, М.Госманов, әсәрнең билгеле булган текстлары нигезендә «ай көзге» һәм «ал көзге» гыйбарәләре турында фикер йөртеп, кулъязмалардагы «ай» дигән язылышның «ал» (ягъни, алтын) эпитетын аңламыйча, аны җиңеләйтеп «ай» рәвешендә күчергәннәр дип язган иде[41]. М.Госманов һәм М.Әхмәтҗанов бастырган текстларның икесендә дә «ал» һәм «ай» сүзләре язылган. Ә М.Гафурида

---

[39] Мирас. – 2002. – № 2. – Б. 21.
[40] Госманов М. Каурый каләм..., 1994. – Б. 242.
[41] Госманов М. Каурый каләм..., 1994. – Б. 242, 271, 278.

бары тик «ай күзге» генә диелә[42]. Без табып өйрәнгән текстта исә «ай күзге» сүзтезмәсе генә очрый, «ал» дигән эпитет монда бөтенләй юк. Менә бу факт «ал» сүзенең «ай» белән алыштырылган булуы турындагы моңарчы урнашкан фикерне расламый.

Дастанның М.Әхмәтҗанов бастырган тексты азагында Түләкнең утыз алты ел ханлык сөрүе турында әйтелә, ә бездәге кульязмада (13б кәгазьдә) ул алты ел дип кенә бирелгән. Бу да яңа текст табылгач пәйда булган табышмакларның берсе.

Басмага әзерләнгән әлеге текстта бүтәннәреннән аермалы тагын бер нәрсәгә игътибар төшә. Бу кульязма текстында егет тә, кыз да тәмлерәк телле, ягъни мәхәббәтлерәк булып гәүдәләнәләр. Чөнки әлеге кульязмада алар бер-берсенә «әй, җаным», «әй, җаным мәхәббәт», «әй, җан мәхәббәте», «әй, җан мәхәббәт юлдашым» сүзләрен, башка текстлардагыга караганда, ешрак һәм күбрәк әйтешәләр. Башка текстларда бу сүзләр берән-сәрән генә очрый. М.Гафури текстында «әй, җаным» дип эндәшкән очрак, гомумән, бер генә[43].

* * *

«Түләк китабы» дастаны теркәлгән кульязманың палеографик үзенчәлекләренә килгәндә, һәр язма истәлектәге кебек үк, анда хаталар, кайбер сүзләрне ялгыш язулар һәм кабатлаулар, аерым хәрефләрнең, иҗекләрнең яки сүзләрнең төшеп калулары күзәтелә. Ике тапкыр яисә ялгышып язган сүзләрен күчерүче үзе үк сызып, төзәтеп куйган мисаллар бар.

Квадрат җәяләр эчендә без өстәгән аерым хәрефләр, иҗекләр, сүзләр кульязманы күчерүче тарафыннан ялгыш төшереп калдырылган дип уйланылган фаразлардан гыйбарәт. Кульязмада «тәгалә» сүзенең «тәга» рәвешендәге кыскартып бирелеше дә тутырып, квадрат җәяләр эчендә язылды.

Тексттагы имля төрлелеге (мәсәлән, сач–чәч, тиде–диде, әйтде–әйде–айды, ашурмаз–ашырмас, булуб–улуб, алуб–алыб–алып, чыкып–чыкыб–чыкуб, айлыйг–айлык, йыллыйг–йыллык, шоңкар–-шынкар–шонкар, бонча–монча, тагъ–тау, кәлеб–килеб, шайәт–шайәд һ.б.) кульязманың үзендәгечә, үзгәртелмичә бирелде.

---

[42] Гафури М. Күрсәтелгән әсәр. – Б. 15.
[43] Шунда ук. – Б. 21.

Дастан текстында хәрәкәләр куелган очрак берничә сүздә генә. Мәсәлән, «камчылату» (4а кәгазьдә) һәм «мөрәүвәр» (9а кәгазьдә).

Аерым сүзләрдә бер төрле үк тартык хәрефләр икешәр мәртәбә язылырга тиеш булганда (йитте, кайттылар, чыкканына, гаделлеге, ишеттеләр) кулъязманы күчерүче кайчак берәр хәреф кенә язган.

Текстта борынгы кулъязмаларга хас булганча, «уау» (و)хәрефенең өстендә өчәр нокта куелган. Ә «син» (س) хәрефенең астында өч нокта кую күренеше сирәгрәк.

«Б» хәрефе урынына еш кына «п» язылган. Бу, бигрәк тә, «ошбу» дигән сүздә күп. Текстны күчереп язган Сибгатулла бине Фәхретдин үзенең исемен теркәгән урында да «ошпу...» диюен алдарак күрсәтеп үткән идек. Мондый язылышны бүтән сүзләрдә (мәсәлән, «бил»не «пил» диюдә) дә күрергә мөмкин. Хәзерге язуга күчергән вакытта кулъязма текстның бу үзенчәлеген үзгәрешсез калдырдык. Бер очракта исә әлеге күренешнең киресе, ягъни «п» урынына «б» белән (мәсәлән, дастан текстының башында «пәри» сүзе «бәри» булярак) язылган. Тексттагы «пулат» һәм «булат» дигән, ике варианттагы язылыш та – шушы ук төрлелекнең чагылышы.

«Тә» хәрефен татарча сүзләрне язганда гадәттә кулланылмаган түгәрәк шәкелдәге (ة) «тә мәрбүтә» белән белдергән берничә очрак булуын да искәртеп китик. Мәсәлән, «түрт» һәм «сөт» сүзләренең ахыргы хәрефләре «тә мәрбүтә» белән язылганнар.

Йомшак « گ» (гяф) хәрефе күпчелек очракта « ک» (кәф) хәрефе белән, кайчагында «ң» белән белдерелгән.

Кулъязмада гарәп хәрефләренең нокталары куелмыйча калган, яисә ялгыш куелган урыннар бар. Мәсәлән, «угыл» сүзендәге «гайн» (غ) хәрефенең өстендәге ноктасы һәр чакта да куелмаган. Берничә урында «йа» (ي) хәрефенең ике ноктасы бөтенләй куелмаган яки ялгыш бер генә нокта төртелгән. Кулъязмадагы берничә җирдә «ч» хәрефенең өч ноктасы урынына бер генә нокта куеп «җ» язылган. Мәсәлән, 4а кәгазьдә «өч» сүзе «өҗ» дип һәм «Акбүзчә» сүзе «Акбүзҗә» рәвешендә теркәлгән. Шулай ук бер ноктаны артык кую яки куймыйча калдыру сәбәпле «хәмаил»(حمايل)не «җәма-

ил» (جمايل) дип, «җанлыйг» (جانليع) сүзен «ханлыйг» (حانليع) дип язулар бар.

Сүз ахырындагы «йа» (ى) хәрефенең язылышы кайбер очракларда «ра» (ر) хәрефенә охшаш шәкел алган.

Берничә сүздә «ләм» (ل) хәрефе гадәти озынлыгыннан кыскарак язылган. Мәсәлән, «һәрамзалык» сүзендә (5а кәгазьдә) һәм «олуглар» сүзендә (13б кәгазьдә).

Аерым язылыштагы «нун» (ن) хәрефе, шикәстә язуы төрендәгечәрәк язылган урыннар бар.

Санап үтелгән палеографик үзенчәлекләр дастанның мәгънәви әһәмиятен һич тә киметмиләр.

Бу җыентыкта «Түләк китабы» дастанының хәзерге татар алфавитына транскрипция элементлары кушылган, барлык тыныш билгеләре безнең тарафтан куелган варианты һәм кулъязманың факсимилесе бирелде. Кулъязманың бит саннары текстта күрсәтелде. Архаик сүзләрнең һәм гарәп, фарсы алынмаларының сүзлекчәсе әзерләп урнаштырылды.

Китап ахырында Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязма тексты белән М.Әхмәтҗанов, М.Госманов һәм М.Гафури бастырып чыгарган текстлардагы сүз һәм гыйбарәләр белән чагыштырма таблицасы тәкъдим ителә. Ул текст вариантларындагы үзенчәлекләрне күзаллау өчен уңайлы. Шунысын искәртик, әсәр текстының дүрт вариантындагы бөтен аерымлыкларны да күрсәтү максатын куймадык һәм, табигый, алар һәммәсе дә әлеге таблицага кертелмәде. Киләчәктә дастанның тәнкыйди текстын басмага әзерләгәндә, шәт, алар игътибарга алыныр.

Ахырда «Түләк китабы» дастаны теркәлгән кулъязма җыентыкка кыскача тасвир бирелде.

«Түләк» дастанының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган әлеге кулъязма тексты матбугатта беренче мәртәбә басыла.

# ДАСТАННЫҢ
# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА
# КҮЧЕРЕЛМӘСЕ

# [ТҮЛӘК КИТАБЫ]

*(4а кәгазь)*[1] «...Безләр өч[2] йегет варалум, ике йегет...[3] суйуб, беремез Акбүзчәне камчылату кәрәк. Ул сагъәт Йилйитмәзнең йөгәнен суйуб алмак кәрәк. Йилйитмәз алып очкай, йә агачка йә ташка сугуб үлтүргәй, аның хурлыгындин[4] котулгаймыз!» – тиделәр.

Өч йегет хәзер килүб, икесе Акбүзчәнең[5] йөгәнен суйуб, берсе кәлеб Акбүзчәне камчылады. Йилйитмәз Акбүзчә Түләкне алыб иллә ...[6] кем, алты-йите көн-төн туктамады. Йитенче иртә, көн чыкар вакытда, бер олуг дәрйаның йакасыйга килеб туктады. Түләкнең һичкайда китмешене белмәгән булмадылар.

Ул сагъәт Түләк карады[7], күрде – бер су пәрисенең[8] падишаһы бар ирде, аты – Чачлар[9] хан атлы[10]. Аның бер кызы бар ирде, гайәт

---

[1] Дастан тексты язылган кулъязма җыентыкта бу битнең өске өлешендә күчерүче тарафыннан биш юл чамасы буш урын калдырылган. Күрәсең, кулъязманы күчерүчегә дастан текстының протографында (ягъни, күчергеч өлге булган нөсхәдә) ниндидер дефект-бозыклык (кәгазе яисә язуы зарарланган) булгандыр. Кәгазь битендәге әлеге буш урынга соңрак гарәп телендәге бер юллык дога язып куелган.

[2] Кулъязмада: «өҗ».

[3] Кулъязмада бу урында бер-ике сүз язарлык буш урын калган. Әсәрнең М.Госманов бастырган текст вариантында әлеге урында «акбүзчәнең җөгәнен» сүзләре язылган (Госманов М. Каурый каләм эзеннән..., Б. 239. Алга таба М.Г. дип һәм бит саны күрсәтеләчәк).

[4] Кулъязмада: «хураэгындин (حوراء عندين). Күрәсең, бу ялгыш протографтагы «хурлы гындин» (حورلى عندين) дип, аерыбрак язылганнан киткәндер.

[5] Кулъязмада: «Акбүзҗәнең».

[6] Кулъязмада бу урында бер сүз язарлык буш урын калган. Дастанның М.Әхмәтҗанов бастырган вариантында (алга таба: М.Ә.) «иллә» сүзеннән соң «очды» сүзе язылган (Мирас. – Б. 19).

[7] Кулъязмада: «арады». «Карады» вариантын әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләре буенча куйдык.

[8] Кулъязмада: «бәрисенең».

[9] Кулъязмада: «Чалчлар».

[10] Кулъязмада: «атаг» (اتاغ). Күчерүче тарафыннан протографтагы «атлы» (اتلى) яисә «атлыйг» (اتليغ) сүзләренең берсе шулай бозып күчерелгән булса кирәк.

сахибе җәмал ирде. Һәр кем ирсә күрсә, гыйшыклыкындин җан биргү тик булур ирде. Ул Чачлар хан падишаһның кызы ошпу Түләкнең тотган вә туктаган йирдә һәр иртә кәлеб чәчен тарар ирде. Үзенең йөзене йөз мең төрлек[11] берлә бизәр ирде. Ул кыз ул йирдә чәчен тарай ултурур ирде. // *(4б кәгазь)* [...][12] атындин төшде. Кызның йанына кәлде. Кыз тоймады, чәченең озын[...][13] бар ирде. Чәчен ике йанына ачуб, йөзендин китәрүб тарай [...][14] кәлеб кызга сәлам бирде. Кыз сачен йөзендин китәрүб торга[...]еб[15] әйде: «Әгәр иңсәмне бирүб торган вакытум булмаса ирде, йөземне сәңа нийәтән күргәзгәй ирдем», – тиде. Түләкнең йөзүн күрде, гайәт зиба йегет торур. Түләккә кыз андагъ гашыйк булды, һич сүз әйткүчегә хале булмады. Ул йирдән китәр дәрманы булмады. Күңлүндә әйден[16] әйде: «Бу йегетне бер заман алдай торайын, шайәт ки котулурмән», – тиде вә «котулуб киткәймән», – тиде. Кызның ул сагъәт Түләкне күреб тәне калтурады[17], һич кузгалур хале булмады. Түләк кызга андагъ кушагъ әйде:

Инеб кәлдүм атымдин,
Имди сәнең үзеңә.
Сәлам бирдүм бән сәнең
Ай тик күреклү йөзеңә.
Гашыйк булдум бән сәнең
Назик зифа буйыңа,
Сүзең әйтче, Сусылу,
Сүзең әйтче, Сусылу!

---

[11] Монда бер сүз төшеп калган. М.Ә. текстында бу урында «бизәкләр» сүзе бар.
[12] Кулъязмада 4б кәгазьнең өске өлешендә уң як почмагы ертылган булу сәбәпле, дүрт юлның башындагы берничәшәр сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «Түләк кызны күреп» сүзләре язылган (Б. 20).
[13] Алдагы искәрмәдә күрсәтелгән сәбәп аркасында берничә сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «озынлыкы алтмыш карыш, буйы» сүзләре язылган (Б. 20).
[14] Алда күрсәтелгән сәбәп аркасында берничә сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «торган вакыты ирде. Түләк» сүзләре язылган (Б. 20).
[15] Алда күрсәтелгән сәбәп аркасында берничә сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «торганы берлән әйләнеп» сүзләре язылган (Б. 20).
[16] Бу сүз артык язылган булса кирәк.
[17] Бу сүз башта «калтураб» дип ялгыш язылып, күчерүче үзе «б» хәрефен сызып «ды» кушымчасын өстәгән.

Кыз Түләккә каршу андагъ әйде:

Сән усалның үзенә[18],
Гашыйк булдуң, бай угълы!
Алтун сыргам бирәйүм,
Бүләк булсун, бай угълы.
Хәстә булуб үләрсән,
Кайтуб киткел, бай угълы,
Кайтуб киткел, бай угълы!

Андин йәнә Түләк кызга кушагъ әйде:

Сәфәр кыйлдук йөз кеше,
Йөгәнем суйды өч кеше.
Атум килде арушыб,
Кулум кәлде карушуб.
Атуң-йулың белмәймән,
Атың әйтче, // *(5а кәгазь)* Сусылу,
Атың нәдүр, Сусылу!

Андин кыз йәнә Түләккә кушагъ әйде:

Атың килсә арушыб,
Кулуң килсә карушыб,
Атың-йулың белмәйсән[19],
Атуң әйтеб бирәйен,
Атуң үзең беләсән:
Һәрамзалык кыйласән,
Сары Мыркас угълы сән,
Гайан Түләк атлигъ сән!
Атуң-йулың белмәйсән,
Кайдин азыб йөрерсән?!
Зифа Түләк, йәш угыл,
Зифа Түләк, йәш угыл!

Андин соң Түләк әйде:

Бер дигәндә бил алган,
Билән[20] салуб суна алган,

---

[18] «Үзенә» сүзе күчерүче тарафыннан кулъязма битнең читенә соңыннан өстәп куелган.
[19] Бу сүз кулъязмада «белмәймән сәң» рәвешендә хаталы язылган.
[20] Кулъязмада: «билне».

Канат какмай каз алган,
Агыз канлыйг бүре алган,
Айагы сибкел төлке алган,
Муйны озун торна алган,
Бога кылы кув алган.
Кош очкыры[21] чүрәкәй[22],
Канат какмай шуны алган.
Арту кошны ашурмаз
Ак шонкардин бизәйен,
Суның кызы, Сусылу,
Сәнең берлән булайын,
Атың нәдүр, Сусылу,
Атың нәдүр, Сусылу?

Андин кыз әйде:

Атум сораб нидәрсән?
Хуш хәмаил[23], хуш йөзек.
Менә сәңа бүләгем!
Безнең йирләр катыдур,
Торалмассән, Түләгем,
Хәстә булыб үләрсән!
Мән дә сәнлек дәгүлмән,
Кайтуб киткел, Түләгем,
Кайтуб киткел, Түләгем!

Андин соң Түләк кызга әйде:

Ар[ту] кошны ашурмас
Шоңкарымдин бизәйем,

[21] «Очкыры» сүзе кулъязмада бер мәртәбә ялгыш язылып, анысы сызылмыйча, янәшәсендә яңадан дөрес итеп язылган.

[22] Кулъязмада: «чүрәкле» (چوراكلى). Контекстка күрә, бу сүзнең «чүрәкәй» (چوراكاى) булуы таләп ителә. Бу сүзләрнең язылышта бер-беренә охшашлыгы буталыш китереп чыгарган булса кирәк. Ягъни, «әй» кушымчасының «әлиф» һәм «йа» хәрефләре «ләм» һәм «йа» буларак кабул ителеп, «ле» кушымчасына әвереләп киткән. Ягъни, «кош очкыры» (кошның җитезе) чүрәкәй – мәгънәви яктан дөресрәк була. Дастанның М.Гафури бастырган вариантында бу сүз «чүрәгәй» дип бирелгән (Б. 13).

[23] Кулъязмада: «җәмаил».

Айлыйг йирдә бер баскан,
Йыллыйг йирдә бер[24] баскан,
// *(5б кәгазь)* Киле-җалы таралган,
Түрт айагы мәрмәр алган,
Аргамакдин бизәйен!
Суның кызы Сусылу,
Сәнең берлән булайын,
Сәнең берлән булайын!

Андин соң кыз әйде:

Акча йөзем күрсәткән,
Ура[у] сачем тараткан,
Толум-буйум бизәткән
Алтун тарак, ай көзгү –
Менә сәңа бүләгем!
Шуны ал да йулың[25] ал,
Кайтуб киткел, Түләгем!
Мән дә сәнлүк дәгелмән,
Ышанмагыл, Түләгем!

Андин Түләк әйде:

Ун ай төгәл күтәргән,
Умыртгадин бөгүлгән,
Ийәле кулдин талпуткан,
Алтун тезгә ултурткан,
Төн йокысун өч бүлгән,
Төнлә торуб имезгән,
Айа[к]дан коймак йидүргән,
Айр[ы] имчәкдин сөт биргән
Анайумдан бизәйүм!
Кара кешкә ураткан,
Алтун тезгә ултурткан,
Ир сакалын үстүргән
Атайумдан бизәйен!

---

[24] Кулъязмада: «берш». Дөресе «биш» булырга тиеш. Чөнки Түләк соңрак әйткән бер кушагында (7а кәгазь) шушы ук сүзләр кабатланган юлда «биш баскан» дип язылган.

[25] Кулъязмада: «йулыңа».

Суның кызы Сусылу,
Сәнең берлән булайын!
Атың әйтче, Сусылу,
Атың әйтче, Сусылу?

Андин кыз әйде:

Хуш хәмаил[26], хуш йөзек
Алмадуң сән, Түләгем.
Алтун сыргам, ай көзгүм –
Йәнә бирдүм бүләгем.
Бүләк бирүб алмассән,
Нидүр сәнең теләгең?
Сүзең әйтче, Түләгем,
Сүзең әйтче, Түләгем!

Андин Түләк кызга әйде:

Хуш хәмаил[27], хуш йөзек,
Зифа буйың – теләгем.
Алтун тарак, ай көзгү –
Мән нитәйен бүләгең?
Бүләк мәңа кәрәкмәз,
Зифа буйың – теләгем!
Сүзем шулдур [...][28]

// *(6а кәгазь)* Андин соң баруб әйделәр Чачлар ханга. Чачлар хан кызына катыйг ачыглануб берәгүне йибәрде, әйде: «Нә өчүн андагъ эш кыйлыб, халкын һәлак кыйла торур? Анда ул йегетне үзе кабул кыйлмаса ирде, адәмнең ничек бу йиргә килүргә нә хале бар ирде? Үзе алуб килүб торур. Имди халыкны нә өчүн һәлак кыйла торур?» – тиде. – «Ул адәмнең догасы мөстәҗаб торур. Баруб кызга әйтүңезләр: сарайның ишеген вә тәрәз[ә]сен ачсун, ул йегетне үз катыйга алсун, гозерләр кыйлыб йахшы дога үтүнсүн!», – тиб, бер кем ирсәне изеде.

Ул кем ирсә килеб атасының сүзүн әйткәч, кыз сарайның ишеген-тәрәз[ә]сен ачды. Ул заман кызның тәнегә көн төшде, күкрә-

---

[26] Кулъязмада: «җәмаил».
[27] Кулъязмада: «җәмаил».
[28] Бу урында, кулъязманың бер кәгазе җуелганлыктан, текстка өзеклек кергән. Мондагы «шулдур» сүзе кулъязманың 5б кәгазе астында кустод буларак язылган.

гендин кереб, аркасындин чыкды. Кыз йануб-көйүб, үлгү тик булуб, булат-сарайга керде. Кызны күреб пулат-сарай казан тик кайнар булды. Шул заман Түләк сарайга керде, кызны күрде, сачендин ураб алды, күтәрүб пулат-сарайның ишегенә сукды, йәнә түренә сукды, кызның гакылы китде. Бер замандин соң кыз исен йыйуб алды. Күзүн ачды, карады, Түләкне күрде, әйде: «Әй, йегет, мән сәне сәүмәзлекдин мондагъ эш кыйлган дәгүлмән. Мән бер падишаһның кызымән, ошпу эш атамга билгүсез булмагай ирде», – тиб, «мондагъ эш кыйлдым мән», – тиб, йегетнең күңлүн бер сүз берлән алды. Йәнә әйде: «Әй, йегет, мончага тигрү эшем хата ирде, имди Хак Тәга[лә]гә // *(6б кәгазь)* шөкер, эшемез күни булды», – тиб, сөйүк-мәхәббәт берлән Түләкнең му[й]ныга кыз кулун салды. «Атамдин дәст[ү]р булуб хәбәр кәлде – сәне үз йанумга алмага», – тиде.

Түләк, кызның бу сүзләрене ишетүб, кызның башына җанын фида кыйлгу тик булды. Андагъ сөйүк-мәхәббәт берлән кыз муйныга Түләк кул салды, мәгәр дигәйсән, күкдин көн берлән ай бер йиргә кушылган[29]! Мәхәббәт-сәвекләре андагъ мәхәббәт берлән сәвешкәнен[30]». Анда кыз Түләккә әйде: «Әй, йегет, имди мәнем гайебемне кичергел», – тиб гозерләр кыйлды, үтүнде. Әйде: «Әй, йегет! Ошпу көн эсселекендин халемез мөшкел булды», – тиб. Әйде: «Имди сән Хак Тәга[лә]дин үтенүб, сез дога кыйлсаңыз, безләр «амин» дисәк, Хак Тәга[лә], шайәт, гафу кыйлыб, бу михнәте безләрдән китәргәй[31]!» – тиб, кыз Түләкнең айагына төшде, үтенде. Түләк андагъ кызга әйде: «Әй, җаным мәхәббәт, бер сагъәт сән сабыр кыйлыб ултургул, мән хәлвәт йиргә барайым, Хак Тәга[лә]дин хаҗәт теләйен, сән һәм теләкдә булгайсән!» – тиде.

Түләк сарайдин чыкуб йир йөзенә инде, хәлвәт йиргә барды, тәйәммем кыйлды, ике рәкәгъәт хаҗәт намазы кыйлды, «Исме әгъзам» догасын укыб, мөһиммә килтүрде, башыны сәҗдәгә куйды. «Илаһи, барча мөшкел эшләр сәңа асан торур», – тиб, Хак Тәга[лә]гә мөнаҗәт кыйлыб, әйд[е]: «Бу кавемдин бу көн эсселеген[32] китәр-

---

[29] Кулъязмада: «кушылгай».
[30] Бу җөмләнең ахыры язылып бетмәгән. М.Ә. текстындагыча дәвам итеп бетергәндә ул «...Аллаһы Тәгаләдин гайре кем ирсә белмәгәй» рәвешендә булырга тиеш.
[31] Кулъязмада: «китәргел».
[32] Бу сүз ике мәртәбә язылган.

гел, мәслихәт бирмәк сәңа асан торур!» – тиб йалбарды ирсә, шул заман куңыз салкун йил исеб, бал дәрйасы, йәнә сөт дәрйасы, // *(7а кәгазь)* йәнә түрт су дә[р]йасы рәүван ага башлады. Тәмамысы иссез булуб өч көн-төн йокладылар. Өч көндин соң бер өлүше һәлак булган көн-төн[33] эсселекендән.

Андин соң Түләк кыз берлән андагъ көндин-көн мәхәббәтләре артук булды. Кыз Түләккә әйде: «Әй, җанум, мәңа дәстүр биргел», – тиде. – «Һәр иртә чыкып, сачүм тарайын, нурд[ид]әм бизәп киләйен!» – тиде. Түләк кызга дәстүр бирде. Кыз һәр иртә хәлвәт чыкып, сачен тарап, йөзүн бизәб килүр ирде.

Бер көн Түләк кызга әйде: «Әй, җанум! Нә[34] йиргә чыкып сачең тарарсән?» – тиде. Кыз Түләккә әйде: «Нә йирдә мәнем сачемдин ураб алдуң, шул йирдә тарармән», – диде. Анд[а] Түләк әйде: «Әй, җанум мәхәббәт, андагъ ирсә, мәнем атым берлән кошумны күрмәймүсән?» – тиб айды. Анда Түләккә кыз әйде: «Әй, җаным! Сән мәңа гашыйк булмышда әймәдеңмү – атымдин бизәйен, кошымдин бизәйен димәдүңмү?» Анда Түләк әйде: «Ул көн андагъ көн ирде, бу көн йәнә үзгә булды. Күрсәң, бар булса, айгыл!» – тиде.

Кыз Түләккә әйде, кушагъ әйде:

Атуң аты Йилмайа,
Имди аңа көн кайа!
Атың торур йабугуб,
Кошың торур бойугуб,
Үзең салыб киткәндин соң
Тәкъи нәчөн сорарсән,
Тәкъи нәчөн сорарсән?

Андин Түләк кызга әйде:

Атум торур ул йирдә,
Мәнем өчен зарыгуб,
Айлык йирдә бер баскан
Түрт айагы талугыб,
Йыллык йирдә биш баскан
Ике күзе карлугуб, // *(7б кәгазь)*

---

[33] Кульъязманың бу урынында «йокладылар» сүзе язылып, күчерүче тарафыннан сызылган.
[34] Бу сүз ике мәртәбә язылган.

Атум алыб килмәгә
Дәрман итче, Сусылу?
Хәлең йитсә, атумны
Алуб килче, Сусылу[35]!
Алыб килче, Сусылу!

Андагъ кыз Түләккә әйде:

Атың, кошың бу йиргә
Килеб йитмәз, бай угълы.
Бу хезмәтең итмәгә
Халүм йитмәз, бай угълы.
Хакдин теләк теләче,
Ишетмәче, бай угълы!
Теләгеңне Хак бирүр,
Давыкмачы[36], бай угълы!
Теләгеңне Хак бирүр,
Давыкмачы, бай угълы!

– тиб, кыз әйде. Андин соң Түләк торды, йәсигъ намазын кыйлды, «Исме әгъзам» догасын укуб, мөһиммә кәлтүрде. Андин соң башын сәҗдәгә куйды[37], әйде: «Илаһи, барча агырлар сәңа асан торур. Атумны, кошымны ошпу йиргә кәлтүрсәң, кодрәтеңдин кәлүр. Мән бичараның хале кем белмәгәй», – тиде. – «Рахманум, сәндин йарый!» – тиб, ул кичә кыз берлән йаттылар. Иртә таң намазы булуб ирде. Намазга торды. Ул вакытта Йилмайа кешнәб ирде, кош шаңкырлады – аваз кыйлды. Ул сагъәт Түләк пулат-сарайның тәрәзәсендин карады: Акбүзчә Йилйитмәз аргамак кәлүб торур, алтун ийәре[38] өстендә, Ак шынкар ийәр[39] кашында күрде. Ул сагъәт Хак Тәга[ләгә] шөкер кыйлыб, башын сәҗдәгә куйуб, әйде: «Илаһи, бу мөлкәт, бу гъинайәт сәндин торур», – тиб.

Атының кашына барды. Аты, кошы Түләкне күрде ирсә, аты селкенде, кошы кагунды – борынгы тик булды. Ул сагъәт Хак Тә-

---

[35] Кулъязмада «Сусылу» сүзе алдына күчерүче ялгыш «бай» сүзен язган.
[36] Давыкмачы – даулама, кычкырма. Давык – дау сүзенең архаик формасы булса кирәк.
[37] Кулъязмада: «кубды». Бу хатаның сәбәбе: «йа» хәрефенең астында ике нокта куясы урынга бер нокта гына куелу.
[38] «Алтын ийәре» сүзтезмәсе кулъязмада «аултун ир» дип, хаталы язылган.
[39] Кулъязмада: «ир».

га[лә] ул пулат-сарайның кашына үлән үстүрде[40]. Һәр кичә анлар йийәр ирде, // *(8а кәгазь)* кичәсенә йәнә үсәр ирде. Йәнә ул кош тагълар[41] тигрәсендә йөрүб кошлар йийүр ирде.

Йәнә Түләк кыз мәхәббәт[е бе]лән каса булып, йөзенә саб-сары булуб чыкды. Үз[е] белмәз ирде. Кыз һәр иртә сачен тарамага чыкыб китде. Анда Түләк кызның ай көзгүсен түшәк өстүндә калмышун күрде. Ачуб карады, үзенең йөзене күрде: саб-сарыйг койылмыш, гайәт усал булмыш иде. «Аһ, дәрига, каса булубмән, үлүм хәлегъә килебмән», – тиде.

Торды, гөлестан дигән уйун йасады, бер думбыра йасады, йәнә бер кыл[42] йасады, бер кубыз йасады, йәнә бер үртәкә йасады. Ул үртәкәнең мөйезләрен алтундин төзеде, айакларын көмешдин төзеде[43], ике күзен гөлдин төзеде. Ул үртәкәне бу җиһан бизәге берлән бизәде.

Торды, тәһарәт төзеде, ике рәкәгъәт хаҗәт намазун укудин [соң], «Исме әгъзам» догасын укуб, мөһиммә кәлтүрде. Башын сәҗдәгә куйуб айды: «Илаһи, хаҗәтүмне сән рәва кыйлгыл. Ошпу төзегәнем уйунум сыйфатыны мәңа сону биргел, йәнә ошпу үртәкәгә җан биргел! Бер Ходайа, ошпу йирдә сәнең хөкемүң берлән гөрифтар булдум, шайәд ки, уйун кыйлсам, күңелүм мәлүл булмагай», – тиб, Хак Тәга[лә]гә йалбарды. Шул сагъәт Хак Тәга[лә] хаҗәтен рәва кыйлды. Уйун сыйфатын бирүб, ул үртәкәгә җан бирде. Түләк имди[44] Хак Тәга[лә]гә шөкер кыйлыб, уйун[45] уйнады, башлады гөлестанун, йәнә думбырасун, кыл[46] кубузун – өчүсүн бергә уй-

---

[40] Кулъязмада: «үшүрде» (اوشوردى). Бу очракта күчерүче гарәп имлясындагы «син» хәрефеннән соң килә торган «тә» хәрефенең ике ноктасын өч нокта буларак кабул итеп протографтан ялгыш күчергән. Ягъни, дөресе (اوستوردى) дип язылырга тиеш иде.

[41] Кулъязмада: «тагъларга».

[42] Кулъязмада: «кыйл».

[43] Кулъязмада: «төзедем». Протографта «төзеде» сүзеннән соң булган «мим»гә охшаш язылган «һәр» сүзен кулъязманы күчерүче «м» (мим) хәрефе буларак кабул иткән булуы ихтимал. Ул вакытта текстның бу урындагы дөрес варианты «...көмешдин төзеде, һәр ике күзен...» рәвешендә булыр иде.

[44] Кулъязмада: «әйде».

[45] Кулъязмада: «әйун».

[46] Кулъязмада: «кыйл».

нар ирде. // *(8б кәгазь)* Үртәкәсе бийер[47] ирде. Барча халык йыйулдылар, сарай эченә сыймаз булдылар, һәр кичә-көндүз Түләк катундин китмәз булдылар. Сарай эчендә торур йир булмады. Тышкары чыкыб ултуруб, мәҗлес коруб, Түләкнең уйуныйга гашикъ булуб, йийәрдин-эчәрдин бизделәр. Иртә торсалар, кич булганун белмәзләр ирделәр. Түләк уйуныйга гашыйк булуб һавадагы кошлар-кортлар, йаландагы ки[йе]кләр – барчасы мондагъ йыйулуб, кичә-көндүз китмәз булдылар. Боланлар, коланла[р], ки[йе]кләр, хәшәрәтләр – барчасы Түләкнең уйуныйга гашыйк булыб, йимәкдин-эчмәкдин бизделәр.

Көнләрдә бер көн Түләк күңелендин зарыйлыг кыйлды: «Әй, Кәрим, вай, Рахим, бонча сарайлар, ки[йе]кләр, хайваннар, хәшәрәтләр берлән мәэва[48] булуб торармән. Йил кузчың тузан басып, сурәтем азыб, җенләр, пәриләр сурәтендә әверелмешмән!» – тиде. Зар-зар йыгълады.

Ул кичә кыз катыйга йатты, тәкъи кызга әйде: «Аһ, дәрига, сәнең зипа сурәтеңә алдануб, адәмләрдин айрулыб, нәсәбсез[49] булдум. Үләр булсам, кайда ата вә кайда ана?» – тиде. «Әй, йегет, гакылың киттемү? Бу гъинайәт, бу дәүләт кемдин торур, белмәзмүсән? Бу дәүләткә йиткүргән падишаһлар падишаһы Тәңре вә Тәга[лә]не онуттыңму? Әйтде: «Айырылганларны кушмак аңа асан торур», – тиб.

Бу сүз илә йегетнең күңелүндән аулады. Йаттылар. Иртә намазга тордылар ирсә, күрде – бер алтун тәхет сарайның кашында улмыш. Тәхетнең // *(9а кәгазь)* өстенә бер олуг, бийек башы һавага чыкган тагъ урынмыш. Сәкез кырлу, дүрт тарафы тимүр берлән тайаган тәхетүндә йукары калкуб сәйа булган. Ул тагъ алтун берлән коршаган, башыны ак мөрәүвәр берлән йапкан. Түгәрәк йанына агач үскән, чыпык урман булган. Барча боланлар, коланлар, айулар,

---

[47] Кулъязмада: «бөйүр» (бойур).

[48] Кулъязмада: «мау» (ماو) дип язылган бу сүзнең дөрес варианты, ахрысы, «мәэва» (مأوا) булгандыр. Аның гарәп телендәге «сыенып яшәү» мәгънәсе контекстка туры килә. Әлеге сүз М.Ә. текстында «сау» дип, ә М.Г. текстында «шад» дип бирелгән.

[49] Кулъязмада: «сәбәбсез» (سبب سز). Бу ялгыш, күрәсең, «нәсәбсез» (نسب سز) сүзенә охшашрак язылудан чыккандыр.

төлкүләр, кошлар, кортлар анда урынмышлар. Бу эшләрне күрүб, кыз берлән Түләк Хак Тәга[лә]гә шөкерләр кыйлып, Түләк тәхеткә кәлеп, алтун тәхет үзә инүб ултурды. Уйунларын кулына алды. Купсаб-купсаб уйнай башлады. Андагъ айтеб дыбсар[50] ирде:

Гөлстаным көйләсүн,
Кыл[51] кубызум сарнасун,
Үртәкәм хуш уйнасун,
Күрмәгә килгән халайыклар
Үзүн-үзе белмәсүн!
Уйнай биргел, үртәкәм,
Уйнай биргел, үртәкәм!
Алтун тәхет урнатган,
Көмешдин[52] айак йараткан,
Тәхет-бәхет төзүткән
Хак Тәга[лә] кодрәте, –
Шөкер кирәк, Сусылу,
Шөкер кирәк, Сусылу!

– тиб уйнар ирде. Анда йыйулган халайык әйделәр: «Бу кем тагы[53] торур? Бу нә атлыйг тагъ торур?» – тиделәр.

Анда Түләк анларга дыбсаб әйде:

Мәнем тауым Балкан тагъ,
Башы һавага чыкган тау,
Тимүр берлә [тайаган][54],
Алтун берлә коршаткан,
Ак мөрәүвәрдин йабкан тау!

– тиб әйде. Аны ишеткән хайваннар, ки[йе]кләр, хәшәрәтләр йыйулуб килүб, башларын түбән салуб тыңлар ирделәр.

[50] Кулъязмада: «дыбсарым».
[51] Кулъязмада: «кыйл».
[52] Кулъязмада: «көмесдин». Чөнки «шин» (ش) хәрефе өстенә куеласы нокталары язылмыйча, ул «син» (س) буларак калган.
[53] Кулъязмада: «тагъ».
[54] Кулъязмада бу сүз язылмыйча калган. Без аны М.Ә. бастырган текстка нигезләнеп өстәдек.

Т[үләк анла]рны[55] күрүб // *(9б кәгазь)* дыбсаб әйде:

Утлар уты май татур, –
Мал-туар, болан сәүгән тау;
Турлавы киң, йире киң, –
Төлке сәүгән Балкан тау!
Йатур[56] йире йакма алтун, –
Йылан сәүгән Балкан тау!
Йийәр йимеше[57] төкәнмәз
Айу сәүгән Балкан тау!
Кабаклары кабарчык, –
Кар сәүгән Балкан тау!
Күл-койусы камышлык, –
Кабан сәүгән Балкан тау!
Йире салкун, йимеше күб[58], –
Кошлар сәүгән Балкан тау!
Сөт дәрйасы су алмас, –
Сукыр[59] сәүгән Балкан тау!
Башымызның өстүндә
Сайә булган Балкан тау!

– тиб уйнар ирде.

Ул җырлар[60], ул эшләр кызның атасы Чачла[р] ханга ишетүлде. Чачлар хан падишаһ кызындин йыраклыгы йите көн-тө[н]лек йир ирде. Түләкне һәм уйунларыны күрмәгә андагъ гашыйк булды. Йимәкдин-эчмәкдин бизде, дийүләрне, пәриләрне Түләкне алмага йибәрде. Пәриләр кәлүб Түләкне алуб китәр булдылар. Анда кыз Түләккә әйде: «Әй, җаным, ошпу үртәкәне алуб бармагул. Ошпу

[55] Кулъязманың кәгазе бу урында дефектлы (тишелгән). «Анлар» сүзенә дә ялгыш бер-бер артлы ике кушымча («-га» һәм «-ны») ялгап язылган.
[56] Кулъязмада: «батур».
[57] Кулъязмада: «йөрүе, эше». Дөрес вариантны әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләренә нигезләнеп өстәдек.
[58] Кулъязмада: «күб» сүзе алдыннан «йук» гыйбарәсе язылып аннары сызылган.
[59] Кулъязмада шулай. М.Г. текстында бу сүз «суыр» (сөркә, байбак) дип (Б. 251), ә М.Ә. текстында «сывыр» дип (Б. 25) бирелгән.
[60] Бу сүзне «хәбәрләр» дип тә укырга мөмкин. Әсәрнең башка күчермәләрендә ул шулай дип бирелгән дә.

газиз сурәтне җанлыйг[61] Хак Тәга[лә] сәңа биребдүр. Нагяһ атам алуб калмасун. Мондагъ нәрсә падишаһларга тансук торур. Үзгә бер үртәкә сурәтене йасаб алуб баргыйл!» – тиде. Түләк аның сүзүн хуш күрде, үзгә үртәкә сурәте йасады. Ул җанлыйг үртәкәсен кыз йанына куйуб китде.

Чачлар хан падишаһга йакын йитәр килә дыбсаб әйде. Уйнай башлады. Түләкнең уйун уйнаганун ишетүб, гашыйк булуб [сабыр]...[62] торалмады. Бер таз колы бар ирде. Аны үзе урыныйга // *(10а кәгазь)* тәхет үзрә ултуртты. Үзе каршы[63] кәлеб тыңлар ирде. Кыз Түләккә атасының сурәтене әйткән ирде. Түләк дыбсаб әйде:

Гөлестанум көйләй[д]үр, –
Думбурам хуш уйнайдур!
Тәхетдә ултурган Чачлар хан
Тәхетдин төшүб тыңлайдур,
Тәхетдин төшүб тыңлайдур!

– тиб.

Андин соң Чачлар хан әйде: «Валлаһи, бу Түләк бүзүрг кеше торур, белекле кеше булмак кәрәк, мәне мондагъ белде», – тиде. Тәхетенә кайтуб ултурды. Түләк килүб йит[т]е, падишаһның сарайыга төшүрделәр. Кырык көн-төн йимәк-эчмәк[64] берлән, уйун-тамаша берлән калдылар.

Андин соң Түләк кызны һәм Балкан тауны, урынуны гайәт сагынды. Чачлар хан падишаһга дыбсаб-кубсаб андагъ әйде:

Балкан тауым монда йук,
Ак ки[й]үкем монда йук,
Ултуруб уйун төзегән
Алтун тәхтем монда йук!

---

[61] Кулъязмада: «ханлыйг» (حانليع). Әлеге сүзне төрлечә язу әсәрнең башка күчермәләрендә дә очрый. Текстта берничә юл түбәндәрәк бу сүз «җанлыйг» (جانليع) дип язылган.

[62] Кулъязманың кәгазе дефектлы булганлыктан, монда бер сүз укылмый. Контекстка күрә, аның «итеп» дигән сүз булганлыгын чамаларга мөмкин. Моңарчы басылган текстларда бу урында «сабыр итә алмады» сүзләре язылган.

[63] Кулъязмада: «кыршуа».

[64] Кулъязмада: «йимәк-эҗмәк».

Җөмлә буйы[65] җофарлы,
Зифа йарым монда[66] йук,

– тиб әйтүб уйнады ирсә, хан падишаһ дийүләргә, пәриләргә бойурды: «Баруңлар, Түләкнең Балкан тауыны алуб килүңләр!» – тиб йибәрде.

Дийүләр бардылар. Хак Тәга[лә] Балкан тауны анларга күргәзмәде, йир берлә төп-төз калды. Дийүләр, пәриләр ул пулат йанындагы олуг таула[р]ны бер-бере үзә куйдылар. Анда Түләк дийү пәриләрнең тауын алуб килгәнүн күрүб, дыбсаб әйде:

Мәнем тауым ул дәгел,
Алтун тәхтем [ул дәгел][67],
Тауны таугa охшатуб,
Пиленә тимүр коршатуб,
Ал[уб] килүб торурлар,
// *(10б кәгазь)* Алуб килә торурлар.

– тиб Түләк әйде исә, андаг Чачлар хан әйде дыбсаб:

Тауны таугa охшатуб,
Тимүр берлә коршатуб,
Монда торгыл Түләгем
Балкан тагъга охшатуб,
Балкан тагъга охшатуб,

– тиб Чачлар хан әйгач, Түләк аңа каршу әйде дыбсаб:

Бары, бары, бары тау,
Барундин[68] бийүк Балкан тау;
Майлаб салган кайушдай,
Йыланы күб Балкан тау.
Сулаб каккан казукдай,
Суыры күп Балкан тау.

[65] Кулъязмада: «бийүе».
[66] Кулъязмада «монда» сүзе ике мәртәбә язылган.
[67] Кулъязманың кәгазе дефектлы булганлыктан, бу ике сүз укылмый иде. Без аларны әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләренә нигезләнеп өстәдек.
[68] Кулъязмада «барундин» сүзе алдына «тау» сүзе язылган. Ләкин ул бу урында артык.

Майлаб[69] салган кайушдай
Йыланы күб Балкан тау.
Айыру тойак, шеш мөйез,
Боланы күб[70] Балкан тау;
Алпан-толапан йөргән
Айу сәүгән Балкан тау;
Барундин бийүк була[71] йөргән
Бүре сәүгән Балкан тау.
Иңсә йоны нәчә алган,
Башы түбән ийүлгән,
Кабан сәүгән Балкан тау;
Кыз угландай сөзелгән,
Төлке сәүгән Балкан тау;
Күб йәшәгән карыйдай,
Карсак сәүгән Балкан тау.
Ойа табар йире хуш,
Кошлары күб Балкан тау.
Дәстүр бирсә Чачлар хан,
Күргем микән Балкан тау!

– тиб Түләк әйде ирсә, анда Чачлар хан әйде: «Китәрмен [тигән][72] Түләкне мончага тикле тоткаймыз?![73]» – тиде. Пәриләрегә әмер кыйлды: «Баруң[ыз! Тү]ләкне[74] сарайына илтүңезләр!» – тиде.

Анда Түләк Чачлар ханга[75] әйде: «[Сез]дин[76] дәстүр булса, кызыңыз кабул кыйлса, // *(11а кәгазь)* атамыз йортына барсак булгаймү?» – тиде. Анда Чачлар хан әйде: «Ир – туган йирендә, эт –

---

[69] Кулъязмада «майлаб» сүзе ялгыш ике тапкыр язылган.
[70] Кулъязма текстында «күб» сүзе һәм аннан соң ук «сәүгән» сүзе язылып, алар икесе дә вертикаль рәвештәге берәр сызык белән сызылганнар. Контекстка күрә, анда «күп» сүзе кирәклеге аңлашыла.
[71] Кулъязмада «була» сүзе ике тапкыр язылган.
[72] Бу сүзне әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләренә нигезләнеп өстәдек.
[73] Кулъязмада: «токтаймыз» (توقتايمز). Ул бер-берсенә охшашрак хәрефләрнең урыннарын бутап күчерү сәбәпле, «тоткаймыз» (توتقايمز) урынына ялгыш язылган.
[74] Кулъязманың бу урыны дефектлы.
[75] Кулъязмада бу сүз алдында «хан» сүзе язылган.
[76] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

ту[й]ган йирендә газиз торур» – тиде. «Атасы йортын сагунмаган ирне – ирме тиб булур?», – тиб дәстүр бирде. Йәнә әйде: «Йортыңызны, сарайыңызны, халкыңызны нитәк кыйлурсыз?» – тиде. Түләк әйде: «Падишаһы галәм, барчаңызның теләгене биргүче Тәңре Тәга[лә] торур». Чачлар хан падишаһ әйде: «Аллаһы Тәга[лә]гә тапшурдук!» – тиб, йибәрде. Пәриләр кызга илтеб табшуруб кайт[т]ылар.

Чачлар хан падишаһның шәһәре тигрәсендә ирде. Түләк килде. Кыз берлән күрүшеб, халь-әхваль сорашдылар. Аты, кошы йабугубдур. Йәнә үртәкәсүн күрде, йабугуб торур, күз йәше, борун сулары агубдур. Шул заман Түләк үртәкәсүн кулына алуб, гөлестанун көйләп, думбурасун уйнады, кыл[77] кубызун зарнаб, үртәкәсен алдына алуб уйнай[78] башлады ирсә, үртәкәсе төзәлеб, күрекләнде, котады. Түләк анда үртәкә бийүгәндә әйтүр ирде дыбсаб:

Ай, үртәкәм, үртәкәм,
Мөйүзләре куш тәкәм,
Мивәләре буш тәкәм.
Күзең йәше агыбдур,
Борун суың агыбдур,
Гарибсен сән, үртәкәм,
Уйнай күңлүм ачылсун,
Уйнай биргел, үртәкәм,
Бии[79] биргел, үртәкәм!

– тиб, төрлүк уйунлар кыйлыб, халайыкның күңелүн ачуб, вә йән[ә кийек][80] кошларың // *(11б кәгазь)* күңелләрен алды вә кинә ачды, шад булдылар.

Бер кич Түләк йәсигы намазы кыйлгандин соң ике рәкәгъәт хаҗәт намазы кыйлды, «Исме әгъзам» догасын укуб, мөһиммә кәлтүрде, башыны сәҗдә[гә] куйды: «Илаһи, барча хаҗәтүмне рәва кыйлдуң, имди бер теләгемне рәва кыйлсаң, ошпу тәхетүң, бәхетүм, халкум, милкүмне йәнә ошпу Балкан тауымны ки[йе]к кошла-

[77] Кулъязмада: «кул».
[78] Кулъязмада: «уйнады».
[79] Кулъязмада: «бийү».
[80] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

ры берлән, урманы-утуны берлән, ошпу бал дәрйа, сөт дәрйасы илә атам өйүнә урнатгыйл. Сәнең кодрәтең олуг торур. Мондагъ эшләрне кыйлмага сәңа асан торур, әй, Җәббарум!» – тиб, күзүндин йәшүн сачеб, Хак Тәга[лә]гә йалбарды, күб мөнаҗәт кыйлды.

Ул кичә йатды. Иртә таң намазы кыйлдылар. Андагъ карады, булат-сарайның тәрәзәсендин көн төшде. Андин борун сарай эченә көн төшә торган дәгел ирде. Тышкару чыкды, кыз караб күрде – бер олуг шәһәр йәнәшәсендә халкы, милке, тәхете, Балкан тауы, урманы, кошы, булат-сарай, бал дәрйасы, дүрт су дәрйасы – барчасы бөйлә килүбдүр. Олуг шәһәр йанында урнамыш. Кыз кайтуб, сарайга керде, Түләккә әйде: «Әй, йегет [белермү]сән[81], бу ни йиргә кәлдүк?» – тиде. Анда Түләк әйде: «Әй, җанум мәхәббәт, мәнем й[ир]үм-йортум ошпу шәһәр торур. Атам йиренә кәлдүк», // *(12а кәгазь)*[82] – тиде. Андин кыз торды, урынларын төзәтте, күшәгәсен корды, ултурды, һичнәрсә сүз әйтмәде.

Ул вакытда ул шәһәрнең падишаһы үлгән. Ул кичәдин борынгы көн ул шәһәрнең олуглары йыйылуб иттифакъ кыйлды, әйделәр: «таң[83] төшкәч шәһәргә һәркем ирсә килсә, падишаһлыкка күтәргәймез», – тиб. Олуг-кечек, алтмыш йәшәрдин алты йәшәргә тигрү киңәш булуб, кем килсә дә, падишаһлыкга күтәргәймез тиб, көтүб торур ирделәр. Ул кичә йатуб, иртә тордылар ирсә, күрделәр: ул шәһәргә йәнәшә бер олуг тагъ урнамыш. Ул тагъ тимүр берлә коршаган да йука[ры ка]лкуб[84] урнадмыш. Ул тәхетнең айаклары көмүшдин, башы гәүһәрдин. Ул тагъны алтун берлән коршаган. Тагъның башыны ак мөрәүвәрдин йапкан. Ул тагъның каршысында[85] бер пулат-сарай торур. Ул пулат-сарайның арт йанындин сөтдин бер дәрйа агуб барур. Ал йанындин балдин бер дәрйа агуб барур, түрт йанындин түрт дәрйа агуб барур. Бер Акбүзчә аргамак ул

[81] Кулъязманың бу урыны дефектлы.
[82] Кулъязманың бу битендә тагын бер мәртәбә «кәлдүк» сүзе кабатлап язылган.
[83] Кулъязмада: «таңда».
[84] Бу урында күчерүче ике сүзне ялгыш кушып, «йукалкуб» дип язган. «Йукары калкуб» сүзтезмәсе 9а кәгазьдә дә бар.
[85] Кулъязмада: «кораушысында».

тагъның төбендә утлай йөрүр ирде. Бер ак шоңкар кош тагъ тигрәсендә очуб, шаңкулаб йөрүр ирде.

Барча олуг-кечек күрделәр: таң-гъәҗәйебкә калдылар. Бу монда пулат-сарайның ийәсен Хак [Тәгал]ә[86] падишаһлыкга бирде булгай», – тиб, гайәт сәвенделәр. Андин соң олуг // *(12б кәгазь)* вәзирләр тордылар. Ул пулат-сарайга бардылар. Ул сарайның ишегендә баруб тордылар. Саклаб торган берничә йегетләрне күрделәр. Мисле ай-көн тик һәркем боларуң күрекләрүн күрделәр ирсә, гакыллары[87] заил булды. Бер замандин соң гакылларын йыйуб алдылар. Анда ул сакчы йегетләргә әйделәр: «Бу сарай кемнең торур?» – тиделәр. Йәнә: «Бу тау кемнең, аты нә торур?», – тиб сурдылар ирсә, анда ул сарайның ишеген саклаб торган йегетләр әйделәр: «Бу сарай Чачлар хан падишаһның кийәве берлән кызының сарай[ы] торур. Вә йәнә тәхет-бәхет, милек, халык аларның торур. Вә йәнә бер тауны Балкан тау тиб әйтүрләр», – тиб әйделәр ирсә, иҗазәт теләп сарайга инделәр.

Ул халайык эчендә Түләкнең атасы Мыркас би[88] һәм бар ирде. Түләк күрешә баруб, атасыйга йитте, кочаклаб күрешде. Түләкнең барча әгъзалары калтураб төште, төсе үзгәрде. Кыз Түләкдин хәфийә берлән сурды: «Ул кеше берлән күрешмәкдә нә өчүн калтураб төштүң, төсең үзгәрде?» – тиде[89]. Анда Түләк кызга әйде: «Әй, җаным мәхәббәт, шул кеше мәнем атам торур, аның берлән сәвеб күрешмәк[ди]н[90] бу[ы]нларымның хәле китде. Аның берлән аның өчен карадум вә калтурадум», – тиде. Кыз белде: кайын а[та]сы[91] имеш.[92]

---

[86] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

[87] Кулъязманың бу урынында һәм моннан соң килә торган җөмләдә бу сүз «гакыйльләре» рәвешендә язылган. Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «гакыйль» сүзе «акыллы» дигән мәгънәне белдерә, ә бу очракта ул контекстка ярашмый.

[88] Кулъязмада бу сүз хаталы итеп, «си» (سى) дип язылган.

[89] Кулъязмада «тиде» сүзе ике мәртәбә язылган.

[90] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

[91] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

[92] М.Ә. текстында бу урында өстәмә берничә җөмлә бар.

Вә йәнә[93] // *(13а кәгазь)* Түләкнең анасының ике имчәгенә сөт тулуб кәлде. Түләк анасы берлән күрешкәндә анасының имчәгендин сөт атылуб чыкды. Түләкнең йөзенә чәчелде. Түләкнең гакылы китде, йыглай[94] йазуб калды. Түләкнең анасы, сөт сачелүб чык[к]анына ойалуб, тугъры карай алмады. Шайәт угылы икәнне анда ук белде, күңелендә әйтүр ирде: «Аһ, дәрига, мәнем бу ике имчәгем сөте галиб булгандин кем, йә им[мә]гә йә кем йөкүлекмү бала[95]», – тиб, йәшүрүн йыглады.

Кыз йәнә Түләкдин хәфийә берлән сурды: «Ул сө[т] сачелгән йөзеңә нә хатун торур?» – тиде. Андин Түләк әйде: «Әй, җан мәхәббәт йулдашым, шул карый хатун мәнем анам торур», – тиде. Кыз белде: кайын ана имеш. Кыз торды, сандук // *(13б кәгазь)* ачды, ике тун чыкарды – алтун-көмүш, гәүһәр берлән мөрәссәгъ кыйлмыш – Түләккә бирде: «Берсен атаңа, берсен анаңа йаб!» – тиде. Түләк бер тунны анасына йабды вә бер тунны атасына йабды.

Халайык анда таң калдылар. Әйделәр: «Әй, солтан угылы, безнең ханымыз үлүб торур. Төнәге көн барчамыз хазер йыйылуб иттифакъ кыйлдук. Ханымыздин угыл-кыз калмады ханлыкга ултуртмага. Барчамыз әйдүк: «Таңдагы көн төш вакытына тигрү һәркем килсә, ханлыкга күтәргәймез», – тиде[к]. «Сезне безгә Тәңре Тәга[лә] кәлтүрде», – тиделәр. – «Имди сәне тәхеткә күтәргәймез!» – тиделәр. Анда Түләк: «Сезнең кабулуңыздин нә белгәймән», – тиде.

Шул заман барча халайык, бер булуб, Түләкне ха[н]лыкга күтәрделәр.

Түләк анда өч йыл хан булуб торды. Андагъ гадел булды. Барча вәйран йортлар төзәлде. Мәгәр куйлар берлән бүреләр бергә йөре-

---

[93] Кулъязмада «Вә йәнә» сүзләре 12б кәгазьнең аскы өлешендәге кустодта күрсәтелүенә нисбәт ителеп язылды. Ләкин күчерүче тарафыннан 13а кәгазьнең өске өлешендә 8 юл чамасы урын язылмыйча, буш калдырылган булган. Соңрак кәгазь битенең әлеге буш урынына дога язып куелган.

[94] Кулъязмада: «йыглады».

[95] Бу җөмләнең ахыры аңлаешсыз.

гү тик булдылар моның гадел[л]еге бәрәкәтендә. Түләкне кем ирдүкен һич кеше белмәз ирде.[96]

Анларга Түләк әйде: «Анларны нә кыйлмак кәрәк?» – тиде. Барча олуглар[97] әйделәр: «Анларны убал итмәк кәрәк» – тиделәр[98]. Андин соң анлар ишет[т]еләр ирсә, качуб орыш йортына керделәр.[99]

Андин Түләк ул дәүләт эчендә ултуруб алты йыл ханлык сөрде. Андин соң // *(14а кәгазь)* Сусылу дөнйадин үткәндин соң Түләкнең угылыны ханлыкга күтәрделәр[100].

Түләкнең[101] угылы дөнйадин үткәндин соң Балкан тау, алтун тәхет, пулат-сарай, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, түрт су дәрйасы – барчасы бер кичдә гаиб булды, йук булды. Һич кайда киткәнен адәм белмәде, хәйран улуб калдылар. Валлаһи әгъләм бис-саваб.

---

[96] М.Ә. текстында моннан соң бер бит чамасы текст бар.

[97] Кулъязмада сүздәге беренче «л» (ләм) хәрефе кыска язылган.

[98] М.Ә. текстында бу урында моннан соң берничә җөмлә бар.

[99] Бу җөмлә М.Ә. текстында юк.

[100] Бу урында ике җөмлә кушылып киткәнгә ошый. Чөнки М.Ә. текстында Сусылу үлгәч икенче елда Түләк вафат була. Аннан соң Түләкнең улын ханлыкка күтәрәләр.

[101] Кулъязмада бу сүз ике мәртәбә язылган.

# «ТҮЛӘК КИТАБЫ» ДАСТАНЫ КУЛЪЯЗМАСЫНЫҢ ФАКСИМИЛЕСЕ


ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ

*4а кәгазь.*


...طلوبی توشدی قز بنگ یانینه کلدی قز تویمادی چاچ بنگ اوزون ...
...ی باریردی چاچین ایکی یانینه آچوب یورودین دین کیتاروب تاراب
... کلب قزنم سلام بردی قز ساچین یورودین دین کیتاروب توری
... ایدی اکر ایکیسام بنی بروب ترکان وقتوم بولماسا ایردی یورنم نی
سنکا نینه [illegible] ایردیم تیدی تولاک بنگ یورون کوردی غایت زیبا ایکیت
... تولاک کا قز انداغ عشیق بولدی کیم سوز ایتکوچی کا حالی بولمادی اول یردان
کیتار دک طاقتی بولمادی کونکلونه ایدی ایدی بو ایکیت نی بیرده ماز آلدای توراین شایت
که قو تولودمن تیدی وقتولوب کیتکای من تیدی قز بنگ اول ساعت تولاک نی کوزی
نی قالطورالدی کیم قونی لوحالی بولمادی تولاک قزنم انداغ قوشتاغ ایدی
اینب کلدوم آطلو سدین ایمدی سنکا اوزنکا سلام بردوم بن سنکا
آی تیک کورکلو یوزنکا عشیق بولدوم بن سنکا نازنین نیغا بویکا
سوزنکا ایتی سوز صلوه سوزنکا ایتیم سوز صلوه قز تولاک کا قارشو انداغ
ایدی سوزی [illegible] اوصال بننک عشق بولدونکیز بای اوغلی آلتون سرکام برایوم
اوزیده
بولاک بولسوت بای اوغلی هسته بولوب اولارسن قایتوب کیتکل بای
اوغلی قایتوب کیتکل بای اوغلی آندین بینه تولاک قزنم قوشتاغ
ایدی سوز تیلد وقت یوردکمشی یورکنم سویدی اوچ کشی آطوم کیلدک
آرو شب قولوم کلدی قاروشوب آطونکیز یالنکز بیلای من آلدا ایتیم

*4б кәгазь.*



*5а кәгазь.*


کیلکی بالی طار آلغان توت ایاقی مہر آلغان ۞ آزغما قدین برایت ۞
سنگ ینگ قزی سنگ صلوقی ۞ سنگز برلان بولدین ۞ سنگز برلان بولاین ۞
آندین صونگ قزایدی آقچم یوزم کورستکان ۞ اوداسا چم ترا طقان ۞ طولوم
بویوم ... تکان ۞ آلتون تراق آی کوزکوہ مونگ سنگا بولاکم ہ سنگ نوبی آلدا یولکا
آل ۞ قایتوب کیتکل تولاکم ۞ منده سنی لوک دکه من ۞ اوشانا عیل
تولاکم ۞ آندین تولاک ایدی آوت آی توبکل کوتارکان ۞ اوم طعادین
بوکو لکان ۞ ایالی قولدین طالبو طقان ۞ آلتون ترنکا اولتور طقان ۞
توربو قسون اوچ بولکان ۞ تونلا توروب ایمزکان ۞ ایادان قوییاق
یدورکان ۞ ایرایمچا کدین سوت برکان ۞ انا یوم دان برایوم ۞ قواکشکا
اولطقان ۞ آلتون ترنکا اولتور طقان ۞ ایر سقالون اوستور
... ۞ انا یوم دان برایت ۞ سنگ سنگز قزی سنگ صلوقی سنگز برلان بولدین ۞
آطلز ایتیچی سنگ سلوقی ۞ آطلز ایتیچی سنگ صلوقی ۞ آندین قزایدی خوش
جمایل خوش یوزلی ۞ الما دونکسی تولاکم ۞ آلتون سرچام آی کوزکوم
یینه بردوم بولاکم ۞ بولاک بروب آلماسی سی ۞ نیدور سنکا تلاکیک ۞
سنکا ... ایتیچی تولاکم ۞ سوزنک ایتیچی تولاکم ۞ آندین تولاک قزنما ایدی
خوش جمایل خوش یوزلی ۞ زیغ بوینکز تلاکم ۞ آلتون تراق آی کوزکوم
من نیتایین بولاکمنگ ۞ بولاک سنکا کراکمان ۞ زیغ بوینکز تلاکم ۞ سوزم

سوزم

*5б кәгазь.*



*6а кәгазь.*



*6б кәгазь.*



*7а кәгазь.*



*7б кәгазь.*



*8а кәгазь.*



*8б кәгазь.*



اوستینه بر اولوغ بیوک باشی بوانغ چقغان تاغ اوستیشی یسکن قولدو دورة
طرافی تمور برلان تیا ان تمتونله یوقادی قالقوب سیا بولغان اول تاغ آلتو
ن برلان قورشاغان باشنی آق مرقد برلان یابقان توکارک یانینه اچ او
او سکان چیق اورمان بولغان بارچه بولانه للار قولان لار آیغلار تولکولار
قوشلار قوره للار آنده اورنشی لار بوایشی لارنی کوروب ق. برلان تولاک
حق تم کا شکر لار قیلیب تولاک تمت کا کلب آلتون تمت اونده اینوب او
لتوردی او یغون لارین تولینه آلدی قوبساب قوبساب اوینادی باشلا
دی آنداغ آییب دبسادرم ایردی گلستانم کویلا سون هم قیل قوبروم ملارنی
سون هم اور تکام حوش ادینا سون هم کوزمکا کیلکان حلایقلار هم
اون وت اودی بلماسون هم اوینای برگل اور تکام هم اوینای برگل اود تکام هم
آلتون تمت اورنا تغان کمیدین ایاق یار اتقان هم تمت بمت تون وتکان ک
حق تم قدرتی شکر کراک سوزسلاو هم شکر کراک سوزسلاو هم تیب اوینار ایردی
آنده بیدلغان حلایق ایدی لار بوکم تاغ ترور بونه آکلیغ طاغ ترور تیدیلار
آنده تولاک اللارنیم دبساب ایدی هم منم طاقوم بالقان طاغ هم باشم طونم چقغا
طاق هم تمور برلان هم آلتون برلان قورشا تغان هم آق مرقدین یابقا
ن طاق تیب ایدی آنی ایشتکان حیوان لار تیک لار حیتلی تالار بیولوب
کیلوب باشلارین تویانه صالوب تمکلار ایردی لار ت[illegible] ـهرنی کوروب

*9а кәгазь.*



*9б кәгазь.*



*10а кәгазь.*



*10б кәгазь.*



*11а кәгазь.*



*11б кәгазь.*



*12а кәгазь.*


ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЬЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ

*12б кәгазь.*



ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ
تولاک نینک اناسی نینک ایکی کوزی ایمچاکینه سوت تولوب کلدی تولاک اناسی برلان کوروشکاننده
اناسی نینک ایمچاکندین سوت آقا طولوب چقدی تولاک نینک یوزینه چاچیلدی تولاک
نینک عقلی کیتتی یغلادی یاتوب قالدی تولاک نینک اناسی سوت ساچلوب چقانینی
اویالوب تونی قادی یملادی شایت اوی ایکانینی آنکه اوشال بلدی
ایتور ایردی آه دریغ منم بو ایکی ایمچاکیم سوت غالب بولغاننین
یا ایمکاکه یا کیم یکولک هو بالاتیب یا تشوردون یغلادی قزینی تولاک
دین خفیه برلان سوره دی اول سوز نسا چلکان یوزنکا نه حاتون
تیدی آندین تولاک ایدی ای جان محبت یولداشم شول قادی حاتون
منم آنام تورور تیدی تولاک بلدی قاین آنا ایمشی تودودی صابندوق
مفتاح الدین
مفتاح الدین


*13а кәгазь.*



*13б кәгазь.*



١٤

صنو صلتو دنیا دین اوتکاندین صونک تولاش نینک اوعلی بی جانلقنی کوتار
دیلار تولاش نینک تولاکنک اوی دنیادین اوتکاندین صونک
بالقان طاقو آلتون تخت یولاط سرای بالدریاسی سوه دریاسی توراه
سود دریاسی بار جنت بر کیچه غایب بولوب یوق بولدی
قایده ییتکانون آدم بلمادی جان اولوب قالدیلار
والله اعلم بالصواب

بسم الله الرحمن الرحيم
الحمد لله رب العالمين والعاقبة للمتقين والصلواة
والسلام على خير خلقه محمد وآله اجمعين اعلم بان
الصلواة العبد مبتلى ان يطيع الله تع فيثاب وبين ان يعصي
الله فيعاقب والابتلاء متعلق بالمشروع وغير المشروع
فعلا وتركا فلا بد من بيان انواع المشروعات وغير المشرو
عات وبيان معانيها واحكامها ليسهل على الطالب ذكرها
وضبطها فنقول بالله التوفيق المشروع على اربعة انواع
فرض وواجب وسنة ومستحب ويليها المباح وغير المشر
وع فيه فالكل ثمانية انواع اما الفرض فما ثبت بدليل قطعي

*14а кәгазь.*

# СҮЗЛЕКЧӘ

**Айак** – савыт.
**Айгыл** – әйт.
**Айлыйг** – айлык.
**Андагъ** – анда, андый.
**Асан** – ансат, җиңел.
**Ашурмаз** – ашырмас.
**Атың-йулың** – исемең, нәселең.
**Әйгач** – әйткәч.
**Әйде** – әйтте.
**Белмәзмүсән** – белмисеңме.
**Берәгү** – бирәү.
**Бер-бере үзә** – берсе өстенә берсен.
**Бизәйен** – бизим.
**Бил** – калкулык.
**Билән** – сал.
**Биргү тик** – бирерлек, бирердәй.
**Бога** – үгез.
**Бонча** – *карагыз:* монча.
**Борун** – элек.
**Бүзүрг** – булдыклы, кодрәтле, данлыклы, зиһенле, дәрәҗәле, олы кеше, зур кеше.
**Валлаһи әгъләм бис-саваб** – чын дөресен Аллаһ белә.
**Варалум** – барыйк.
**Галиб булгандин** – җиңгәннән.
**Гайан** – билгеле, ап-ачык, күзгә күренеп торган.
**Гаиб булу** – юкка чыгу.
**Гарибсен** – кайгылы, сагышлы, моңсу.
**Гөрифтар** – дучар.
**Гъинайәт** – ярдәм.
**Давыкма** – даулама, кычкырма.
**Дәгел** – түгел.
**Дәгелмән (дәгүлмән)** – түгелмен.
**Дәрига** – ни кызганыч, ни аяныч, ни үкенеч.
**Дәстүр** – рөхсәт.
**Дыбсаб** – җиңелчә көйләп, йомшак тавыш белән.
**Җәббар** – зур куәт иясе, Аллаһ.
**Заил булу** – бетү.
**Зийадә** – артык.

**Зарнаб** – *карагыз:* сарнап.
**Иҗазәт** – рөхсәт.
**Изеде** – җибәрде, юнәлтте.
**Имди** – инде.
**Имеш** – икән.
**Инеп (инүб)** – иңеп, төшеп.
**Ирде** – иде.
**Ирдүкен** – икәнен.
**Иттифакъ** – берләшү.
**Йакасыйга** – якасына, буена, ярына.
**Йөгән суйу** – йөгән салдыру.
**Йөрегү тик** – йөргәндәй.
**Йийәр** – ашар, тукланыр.
**Йыллыйг** – еллык.
**Кабак** – кыя, тау сырты.
**Кабарчык** – кабарынкы.
**Канлыйг** – канлы.
**Карлугуб** – каралып, кайгыдан моңланып мәгънәсендә.
**Карсак** – төлкенең аерым төре.
**Карый** – карт.
**Каса** – дучар булу, авыруга сабышу.
**Катигъ** – каты, бик нык.
**Катыйга** – катына, янына.
**Катындин** – каршыннан.
**Кашына** – каршына.
**Кәлеб** – килеп.
**Кәрим** – юмарт, газиз, Аллаһның күркәм исемнәреннән берсе.
**Кем ирсә** – кеше, берәү.
**Кинә** – янә, тагын.
**Киткәймән** – китәрмен.
**Кув (ку)** – аккош.
**Кузчы** – кузгатучы, күтәрүче.
**Котады** – җанланды, хәрәкәткә килде.
**Көн** – кояш.
**Кубсаб (купсап)** – җырлап, көйләп.
**Куңыз** – коры, салкын.
**Кушагъ** – җыр.
**Күни** – дөрес, яхшы.
**Күргем** – күрермен.
**Күреклү** – күрекле, чибәр.

**Күрмәзмүсән** – күрмисеңме.
**Күшәгә** – чаршау, пәрдә, бөркәнчек.
**Кыйлгу тик** – кылырдай.
**Мәлүл** – кайгылы.
**Мәңа** – миңа.
**Мәэва** – сыенып яшәү.
**Мивә** – ми.
**Монча (бонча)** – моңарчы, шул хәтле, күпме.
**Мөйез** – мөгез.
**Мөрәссәгъ** – алтын яки асылташлар белән бизәлгән.
**Мөрәүвәр (мәрварид)** – энҗе.
**Мөстәҗаб** – кабул.
**Мөһиммә** – мөһим эш, бурыч.
**Нагяһ** – көтмәгәндә, кинәт.
**Нәүгъ** – төр.
**Нәчә** – ничә.
**Нәчөн** – ни өчен.
**Нигъмәт** – байлык.
**Нийәтән** – ният белән, бик теләп.
**Нитәк** – ничек.
**Нурдидә** – нурлы йөз, күз нуры.
**Очкыр** – җитез.
**Падишаһы галәм** – дөнья патшасы.
**Рахим** – рәхимле, Аллаһның күркәм исеме.
**Рәва** – кабул, яраклы.
**Рәүван** – кире.
**Сарнаб (зарнаб)** – такмаклап, бер-бер артлы тезеп, кызу темп белән әйтү.
**Сахибе җәмал** – чиксез гүзәллек иясе.
**Сач** – чәч.
**Сәвеб** – сөеп.
**Сәвенү** – сөенү.
**Сәйа (сайә)** – күләгә.
**Сәкез** – сигез.
**Сону биргел** – ирештер.
**Сөзелгән** – нәфис.
**Суна** – ата үрдәк.
**Сурды** – сорады.
**Сырга** – алка.
**Тайаган** – коршаган.
**Талпыту** – тибрәтү.

**Тәкъи** – тагын.
**Тәхет үзә** – тәхеткә.
**Тигрәсе** – тирәсе.
**Тигрү** – кадәр, тикле.
**Тиде** – диде.
**Тип** – дип.
**Төнәге көн** – төнәген, кичә.
**Турлау** – ауларлык кошлар, киекләр даирәсе.
**Түрт** – дүрт.
**Тышкары (тышкару)** – тышка.
**Убал** – гаепле, гөнаһлы, бәхетсез, җәза.
**Ултурур** – утырыр.
**Урау** – үрелгән.
**Урнатгыйл** – урнаштыр.
**Урнатсаң** – урынлатсаң, урнаштырсаң.
**Урынмыш (урнамыш)** – урнашкан.
**Усал** – зәгыйфь, ямьсез, начар.
**Үзә** – өстенә.
**Үзрә** – өсте.
**Үлгү тик** – үләрдәй.
**Үлтүргәй** – үтерер.
**Хәлвәт** – аулак.
**Хәстә** – авыру.
**Хәфийә** – яшертен, сер.
**Һәрамзалык** – ялган, алдашу.

# ДАСТАН ТЕКСТЛАРЫНДАГЫ КАЙБЕР СҮЗЛӘРНЕҢ ЧАГЫШТЫРМА ТАБЛИЦАСЫ

| ***Милли китапханә нөсхәсендә (1761т)*** | ***М.Әхмәтҗановта (Мирас. – 2002. – № 2)*** | ***М.Госмановта (Каурый каләм..., 1994)*** | ***М.Гафурида (Уфа, 1910)*** |
|---|---|---|---|
| *4а кәгазь* | | | |
| көн чыкар | көн тугар | | |
| йакасыга | йаныга | | |
| Чачлар | Җаждар | Чачдар | Чачуар (Саче вар) |
| тик | дик | | |
| *4б кәгазь* | | | |
| төште | инде | инде | |
| алдай торайын | алдайын | | |
| котулурмән | котылып китәйен | котылып киткәймән | |
| хале | дәрманы | хәстә | |
| кушагъ | кушак | йарышып | |
| хәстә | госса | | |
| арушыб | йарышып | | |
| *5а кәгазь* | | | |
| Мыркас | Мирказ | Миркас | |
| арту | ату | артык | артык |
| ашурмаз | очырмаз | ашырмас | асрамаз |
| сибкел | сипкел | силбәк | сылтак |
| хуш җәмаил | куш җәмаил | куш хәмаил | хуш әмилек |
| айлыйг | айлык | айлык | |
| йыллыйг | йыллык | йыллык | |
| *5б кәгазь* | | | |
| мәрмәр алган | каралган | бер алган | майрылган |
| бизәйен | бизәйем | бизәйен | |
| булайын | булайым | | |
| бизәткән | сылаткан | сылаткан | |
| ай көзгү | ал көзге | ал көзге | ай көзгү |
| умыртгадин | уң утакдин | уңгурткадин | агырлыкдан |
| ийәле кулдин тал-<br>путкан | аләли кулда тал-<br>чыкган | хәлал кулы тал-<br>чыккан | |
| тезгә | кийездә | тезегә | |
| ир сакалын | айыры сакал | айры сакал | айры сакал |
| коймак | каймак | каймак | каймак |
| анайумдан | инәйдәнмен | анамдин | анамдан да |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ай көзгүм | ал йөзкем | ал йөзек | |
| алмассән | алмазсың | алмайсән | |
| сәнең | мәндин | сәнең | |
| теләгем | бизәнең | бизәгел | |
| | | | |
| *6а кәгазь* | | | |
| хале | дәрманы | хале | |
| килүб торур | килепдер | килеп торыр | |
| кыйла торур | кыладыр | кыла торыр | |
| кызга | кызымга | кызыма | |
| кем ирсә | кемсәнә | кем ирсә | |
| изеде | йибәрде | иза йибәрде | |
| әйткәч | әйгач | әйткәч | |
| йануб-көйүб | йанып | йанып | |
| сукды | орды | | |
| күңлүн бер сүз | күңлесин алды | күңелен бер сүз | |
| берлән алды | | илә алды | |
| тигрү эшем хата | кадәри... эшемез | тигрү эшемез хә- | |
| ирде | хәтәр иде | тәр ирде | |
| | | | |
| *6б кәгазь* | | | |
| фида | корбан | корбан | |
| кушылгай | кушылды | кушылган | |
| кичергел | кичрү биргел | кичергел | |
| җаным мәхәббәт | җан мәхәббәте | җаным мәхәббәте | |
| кыйлып ултургул | кыйлгыл | кылып ултыргыл | |
| булгайсән | булгыл | булгайсән | |
| мөшкел эшләр | мөшкелләр | мөшкел эшем | |
| кавемдин | кавемни | кауемдин | |
| мәслихәт | сихәт | сихәт | |
| куңыз | коңгыр | куңгыр | |
| | | | |
| *7а кәгазь* | | | |
| көн-төн | кичә-көндез | көндез-кичә | |
| булган | булмышлар | | |
| артук булды | зийадә улып | артыграк булды | |
| әй, җаным | әй, йегет | әй, йегет | |
| тарайын | тарап | тарап | |
| күрмәймүсән | күрмәзмесән | күрмәзмүсән | |
| тиб айды | тиде | | |
| мәңа | бәңа | мәңа | |
| әйтмәдеңмү | аймадыңмы | әйтмәдең[ме] | |
| бизәйен | бизәрмен | бизәйен | |
| андагъ көн | аның кебек | аның кебек | |
| күрсәң, бар булса | күрүр булсаң | күрсәң булса | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| йабугуб | абыгып | йабыгып | |
| бойугуб | йабыгып | | |
| нәчөн | нигә | нәгә | |
| торыр ул йирдә | торса ул йанда | торур ул йанда | |
| түрт | дүрт | | |
| йирдә биш баскан | йирне караган | | |
| карлугуб | карыгып | калыгып | |
| *7б кәгазь* | | | |
| килмәгә | килергә | килмәгә | |
| теләче | теләгел | теләче | |
| давыкмачы | тарыкмачы | кайгырмачы | |
| мөһиммә | мәһим | мәхкәм | |
| шаңкырлады, аваз | шангылтаб аваз | шоңылдап аваз | |
| кыйлды | бирде | кылды | |
| кашына | катына | кашына | |
| йийәр | ашар | йийәр | |
| *8а кәгазь* | | | |
| каса | гасәлдә | хәстә | |
| булыпмән | булып | булды | |
| хөкемүң | хикмәтең | хөкемең | |
| сыйфатын | сәнгатене | сәнгатене | |
| *8б кәгазь* | | | |
| сыймаз | йыгъмаз | сыймаз | |
| йийәрдин-эчәрдин | җийарындин, эчә- | ашамакдин, эч- | |
| | рендин | мәкдин | |
| белмәзләр | белмәз | белмәс | |
| йил кузчың | йалкыз җаның | йил кузса | |
| әверелмешмән | әверелер ирмеш- | | |
| | мен | | |
| катыйга | катына | катына | |
| адәмләрдин | асылларымдин | адәмләрдин | |
| аулады | авытдый | ауытды | |
| *9а кәгазь* | | | |
| коршаган | кушаган | коршаган | |
| мөрәүвәр | мәрвәр | мәрвар (мәрваред) | |
| чыпык | чыбыклык | чыбыклык | |
| уйнай биргел | бии биргел | бийи биргел | |
| нә атлыйг | ни тигән | ни | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| *9б кәгазь* | | | |
| май | мал | май | |
| турлавы | тулагы | кырлары | |
| падишаһларга | аңа | падишаһга | |
| үзгә | үзеңә | ул йиргә (уйигә) | |
| *10а кәгазь* | | | |
| сурәтене | сыйфатын | сыйфатын | |
| бүзүрг | бизәк | бер дәррәк | |
| җофарлы | җопарлык | | |
| *10б кәгазь* | | | |
| сулаб каккан | сублаб какган | сублап каккан | сулаб каккан |
| сөзәлгән | сузылган | сөзелгән | сөйләшкән |
| ойа табар | ойа итеп | | ойа йасар |
| *11б кәгазь* | | | |
| бер кич | бу кичә | | |
| урманы-утуны | урманы-утлавы | | |
| *12а кәгазь* | | | |
| арт йаныидин | артындин | | |
| шаңкулаб | шаңгылтай | | |
| сәвенделәр | сүвенештеләр | | |
| *12б кәгазь* | | | |
| җаным мәхәббәт | җан мәхәббәтем | | |
| *13а кәгазь* | | | |
| анасы | инәсе | | |
| күрешкәндә | күрешмәкдә | | |
| нә хатун торур | ни хатын ирде | | |
| анам | инәм | | |
| *13б кәгазь* | | | |
| чыкарды | алды | | |
| төнәге көн | түнәкөн | | |
| күтәргәймез | күтәрәле | | |

# ДАСТАН ТЕРКӘЛГӘН
# КУЛЪЯЗМА ҖЫЕНТЫККА ТАСВИР

Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1761 т» шифры белән саклана торган бу кулъязманың дастан тексты язылган өлеше турында кереш мәкаләбездә тәфсилләп язылды. Шул ук җыентыкка гомуми тасвир биреп һәм бүтән битләренә дә кыскача күзәтү ясап китәбез.

Кулъязма җыентык Россиядә эшләнгән саргылт кәгазьгә көрәнсаргылт кара белән язылган. Сакланышы уртача. Су билгеләре (филиграньнәр) 13, 18, 30, 37, 38 кәгазьләрендә 1832 елны һәм 23 кәгазендә 1834 елны белдерә. Кулъязманың зурлыгы 17х20,5 см, биттә текст язылган мәйдан 13х15,5 см тәшкил итә. Җыентыкның гомуми күләме ике яклары да язулы 44 кәгазьдән гыйбарәт. Тышлыгы юк. Кәгазе юешләнүне кичергән, җыентыкның аскы сул як почмагы караңгы шәмәхә кара түгелеп зарарланган, 1–4 кәгазьләренең өске сул почмаклары теткәләнгән, ертылган хәлдә. Берничә битендә кәгазе үтәли тишелгән дефектлары бар. Арадагы кайбер битләре төшеп югалган. Берничә бите тегелгән җепләренә бик аз гына эләгеп тора, кайберләре теккән урыннарыннан бөтенләй ычкынганнар.

Җыентыктагы төп текстларны мулла Сибгатулла бине мулла Фәхретдин Багданов күчереп язган. Бу исем кулъязманың 36б кәгазендә теркәп куелган. Аннан тыш, җыентыктагы 13а кәгазьнең өске өлешендә «Хәйрулла, Габдулла Әхмәдев, Әхмәдулла» дигән исемнәр һәм аскы өлешендә берничә мәртәбә «Мифтахетдин» исеме язылган. Болары каләм шомартыр өчен генә, очраклы язулар. 44б кәгазь читендә тагын бер кеше исеме бар: «кәтәбәһе Мөхәммәдкәмал бине мулла Сәфәр...» (ахыры танылмый). Җыентыкның 12б кәгазенең өстендә кызыл кара белән «фәлән бине фәлөнга» дигән сүзләр язып куелган.

Кулъязманың язуы (почеркы) тотрыксыз, кайбер текстлар гарәп имлясының тәгъликъ, кайсылары нәсех төре белән язылган. Гомумән, 1–14 кәгазьләрдәге текстны, нигездә, нәсехкә якын тәгъликъ-

ка, 14–19 һәм 21–28 кәгазьләрдәгесен – нәсехкә, 30–44 кәгазьләрдәген – тәгъликъка шартлы рәвештә нисбәт итәргә мөмкин. Әлбәттә, җыентыкның язуы югары сыйфатлы каллиграфиягә ия булмаганлыктан, аерым бер язу төренә генә нисбәт итеп булмый. Чөнки бу кулъязмада гарәп язуының сөлес, шикәстә, дивани һәм башка төрләренең элементлары да катышып киткән.

Текстта урыны-урыны белән хаталы яисә кабатлап язылган сүзләр бар, язып яңадан төзәтелгән сүз һәм аерым сүзтезмәләр дә очрый. Кәгазьләрнең түбәнге өлешендә кустодлары бар, тик алар тотрыклы түгел. Кайбер битләрдә язылмыйча буш урыннар калдырылган. Кулъязма җыентыкның «Түләк китабы» дастаны өлешендәге палеографик үзенчәлекләр кереш мәкаләдә җентекләбрәк тасвирланды.

Җыентыкның 1а–2б кәгазьләрендә төрки-татарча шигъри әсәрнең ахыргы өлеше теркәлгән.

Сакланган текстының башы:

*«Ходайым тәкъдире һич әзергә булмас.»*

Ахыры: *«Насыйб иткел, ходавәндәм, гатаны,*
*Кичүргел ошпу сүзләрдән хатамны.»*

2б–3б кәгазьләрдә төрле дәва-сихәт догалары язылган.

4а–14а кәгазьләрдә «Түләк китабы» дастаны.

Башы: *«Безләр өҗ йегет варалум, ике йегет...»*

Ахыры: *«Һич кайда киткәнен адәм белмәде, хәйран улуб калдылар. Валлаһи әгъләм бис-саваб».*

14а–18б кәгазьләрдә гарәп телендә намаз тәртипләре аңлатылган. 18б кәгазьдә шәехләрнең каберләре турында татар телендәге язма фрагменты теркәлгән.

19а–21а кәгазьләрдә «Сәрхәбад догасы» һәм башка төрле дәвасихәт, әфсен һәм өшкерү догалары язып куелган.

21б–23б кәгазьләрдә татар телендә намаз тәртипләре язылган.

24а–28б кәгазьләрдә татарча тәҗвид кагыйдәләре теркәлгән. Андагы татарча сүзләр дә хәрәкәләр белән язылган. Мәгълүм булуынча, татар текстларында гарәп хәрәкәләре сирәк кулланылган.

29а–29б кәгазьләрдә төрле дәва-сихәт, өшкерү догалары язылган.

30а–44б кәгазьләрдә Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәре теркәлгән. Аның башындагы бите төшкән.

Сакланган текстының башы: *«...нлар. Әл-кыйсса. Баражҫ вәзир баруб өндәде...».*

Ахыры: *«сычкан йылында Ташбилге авылында бу рисалә тәмам булды. Тәммәт тәмам».*

Кулъязма җыентык, кыскача тасвирлаганда, шушылардан гыйбарәт.

## РЕЗЮМЕ

Вторая книга серии «Татарская археография» представляет собой публикацию древнетатарского эпического произведения (дастана) «Туляк китабы», сохранившегося в рукописном сборнике второй четверти XIX века, и хранящегося в настоящее время в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Составителем сборника был мулла Сибгатулла Багданов (1820–1875). Он с 1857 года был ахуном Спасского уезда Казанской губернии и являлся избранным членом (заседателем) правления Оренбургского мусульманского духовного собрания.

Списки дастана о Туляке сохранились в небольшом количестве. Научной среде они были известны лишь в четырех списках, один из которых – полный – переписан в 1877 году, другой – средней сохранности – относится также ко второй половине XIX века. Третий – фрагментарный список относится ко второй половине XVIII века и один дефектный список без даты.

Публикуемый экземпляр является пятым списком. Данный рукописный сборник был приобретен автором этих строк 11 апреля 1996 года в селе Камышлы Камышлинского района Самарской области во время археографической экспедиции.

О драгоценной находке впервые нами было сообщено в татарской газете «Бердэмлек» (2–8 июля, 1996 г.), издающейся в Самаре. Позже – в 2002 году краткая информация была опубликована в журналах «Библиотечный вестник» (2002. – № 1) и «Казан утлары» (2002. – № 3).

В дастане описывается романтическая история любви Туляка – младшего сына хана и дочери правителя подводного царства Сусылу. Любовь приводит Туляка в их владения, но его одолевает тоска по родине. И влюбленные возвращаются в земной мир, где Туляка избирают ханом. Ему было суждено стать справедливым и мудрым правителем. Как сказано в дастане, «даже овцы с волками стали ходить вместе». Основная идея народного любовно-героического эпоса – любовь к родной земле, к родине способна преодолеть трудности и преграды.

Кроме текста «Туляк китабы» в данном сборнике представлена статья, посвященная историографии изучения письменных вариантов эпического произведения, а также археографический обзор и палеографическое описание текста дастана. Текст произведения представлен в переложении на современную татарскую графику. Книга включает в себя также факсимиле рукописи. В сборнике содержатся словарь и сравнительная таблица публикуемой рукописи с ранее опубликованными вариантами текста эпоса известным писателем Мазитом Гафури, учеными М.А.Усмановым и М.И.Ахметзяновым.

**ЭЧТӘЛЕК**

*Мәрданов Р.* «Түләк» дастанының Татарстан Милли китапханәсендәге кулъязма нөсхәсе ........ 3

ДАСТАННЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА КҮЧЕРЕЛМӘСЕ ........ 20

«ТҮЛӘК КИТАБЫ» ДАСТАНЫ КУЛЪЯЗМАСЫНЫҢ ФАКСИМИЛЕСЕ ........ 42

Сүзлекчә ........ 63

Дастан текстларындагы кайбер сүзләрнең чагыштырма таблицасы ........ 67

*Мәрданов Р.* Дастан теркәлгән кулъязма җыентыкка тасвир ........ 71

Резюме ........ 74

ЭПОС О ТУЛЯКЕ
*(на татарском языке)*

Автор-составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 20. 06. 2008. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 500 данә. Заказ № 245.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 20. 06. 2008. Формат 60х84 1/16.
Тираж 500 экз. Заказ № 245.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники
редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.